Рөстәм Закуан

Авыл моңы

**Шигырьләр**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
З-88

**Зәкуан Р.Г.**

Авыл моңы: шигырьләр / Рөстәм Зәкуан. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 148 б. — 3000 д. — ISBN 978-5-298-01679-7

Шагыйрь Рөстәм Зәкуан үзенең бу китабында да туган җир, авыл темасына тугры калып, аның матурлыгын, кешеләрнең күңел җылысын үз шигырьләрендә ачып бирергә омтыла. Китапта шулай ук шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы урын алган.

ISBN 978-5-298-01679-7
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Зәкуан Р.Г., 2008

## КҮҢЕЛЕНДӘ ШИГЫРЬ ЙӨРТКӘН

Рөстәм Зәкуан шигърияткә соңлап кына килеп керде. Илле яше тулып килгәндә генә беренче китабын чыгарды. Шигъбрияттән читтә үткән еллары өчен дә язып калыйм дигән кебек ашыга-ашыга шигырь арты шигырь иҗат итәргә тотынды. Менә, Укучым, Синең кулыңда инде аның икенче китабы.

Шигърияттән читтә үткән дип яздым да, ялгышам бугай дигән уй килде башыма. Язылась шигырьләре өчен сүл җыйган еллары бугай ул чоры Рөстәмнең. Юк, һич тә әрәмгә үткән еллар түгел. Узган ел без бер төркем язучылар Азнакай районына — Рөстәм Зәкуанның туган якларына — татар әдәбияты көннәренә кайттык, район үзәгендә, авылларда укучылар, әдәбият сөючеләр һәм, гомумән, халык белән очрашуларда катнаштык. Бу төбәк халкының горурлыгы булган атаклы Чатыртау түбәсенә мендек. Бик матур, галибанә манзара ачыла Чатыртау түбәсеннән тирә-якка күз салгач. Язмас җиреңнән яза башларсың бу сокландыргыч күренешләр тәэсирендә! Иң истә калганы Рөстәмнең туган авылы Үчәлледә очрашулар булды. Рөстәмнең әнисе Римза апа Закирова кырык елдан артык авылда китапханәче булып эшләгән икән. Авыл халкы бик яраткан, хөрмәт иткән булган үзен. Кызганыч, Римза апа да, Рөстәмнең әтисе Газизьян абзый да бүген инде дөньяда юклар, бакыйлыкка бик иртә күчкәннәр. Без Азнакайга килгән көннәрдә халыкның ихтирам билгесе итеп Римза апа эшләгән китапханәгә аның исемен бирү, китапханә урнашкан бина диварына аның хөрмәтенә мемориал такта ачу тантанасы булды.

Менә каян килә икән Рөстәмдә әдәбиятка тартылу. Ул китапка хөрмәт зур булган гаиләдә тәрбияләнеп үскән икән! Тиккә генә мәктәпне бетергәннән соң Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга кермәгән булган.

Язмыш Р.Зәкуанны журналистикадан аерып авыл хуҗалыгы белән бәйләсә дә, күңелендә шигырь йөрткән ул. Һәм менә Казанга күчеп килгәч, кулына каләм алып, авылда үткән еллары өчен дә икеләтә, өчләтә үҗәтлек белән шигырьләр язарга тотынган. Ә язганнары — авыл, аның кешеләре, аларның борчулары, шатлыклары, заман проблемалары, туган як табигатенең матурлыклары, һәм, әлбәттә инде, мәхәббәт.

Сәясәт бәйли кулымны,
Ябышкак сыргак сыман,
Күңелемне богауларда
Тоткан бер тозак сыман.

Өзеп ташлап богауларны,
Кырга килә чыгасым.
Кушылып бүз тургайларга,
Кырлар җырын җырласым!

*(«Урыйсы килә кырларны»)*

дип яза ул, илдә авыл хуҗалыгына карата дөрес сәясәт алып барылмавына борчылуын белдереп.

Тауга карап тау булмадым,
Тауларны тик яраттым.
Таудай башны горур тотып
Яшәргә дип җан аттым.
*(«Тауга карап...»)*

Монысы исә шагыйрьнең тормышка, яшәүгә мәхәббәт белән сугарылган дистәләгән шигырьләреннән бер үрнәк.
Әйе, китапны тулысынча укып чыккач, Син, Укучым, шагыйрь күңелендәге хисләр дулкынында кайнагандай булырсың, үзеңне дә битараф калдырмаган темалар белән очрашырсың һәм иң мөһиме, рухи ләззәт алырсың дип өметләнәм.
*Рафис Корбан*

# Гомерләр үтә икән...

*Олы юлда калган эзләремне*
*Сагынганда салам көйләргә.*
*Халкым җырын саклый алсам иде*
*Бездән соң да җиргә килгәнгә.*

## ***И туган җир***

Яшәсәм дә, газиз туган ягым,
Бүген читтә синнән, ялгызым,
Сине уйлап ата ал таңнарым,
Сине сагынып кайтам яз-көзен.

Сөендерә мине һәр шатлыгың,
Хәсрәтеңә мин дә кайгырам.
Яңгыр көтсәң, теләп дога кылам,
Җил-давылы үтсә, борчылам.

Хәлем бетсә ятып таш калада,
Зимагурдай кайтып егылам.
Чишмә суларыңнан хәл алам да
Алга карап кабат юл чыгам.

Сиңа атап бүген җырым язам,
Җырларыма синнән моң алам.
И кадерле, газиз туган җирем,
Читтә йөргән мин бит бер балаң!

## ***Чатыртауга* менсәм***

Чатыртауга менсәм, җаным ургый,
Йөрәк уйный, сыймый кочакка.
Тамырларда гүя каным кайный,
Яшьлек калган гүя шул якта.

Кошлар кебек канатларны җәеп,
Кырлар аша килә очасым.
Туган җирнең гүзәллеген тоеп,
Бар дөньяны килә кочасым.

Күпләр сагына — кабат кайтыр иде,
Чатыртаулы туган нигезгә.
Шул нигезгә кайтып егылырга,
Белмим, кайчан язгандыр безгә.

Шуны беләм: бер көн туган якта
Юлларымның кайтып туктасын.
Бүген ләкин язмыш читтә йөртә,
Тыгыз бәйләп үзенең путасын.

## *Син кайдан?*

Кай яктан дип сорашабыз,
Очраса яңа дус-ишләр.
Үчәллемдә — туган нигез,
Илбәгендә узды гомер,
Азнакайда — кылган эшләр.

Ниләр кылдым, ниләр кырдым?
Нәрсә калды ул еллардан?
Яхшылыгы күбрәк, беләм,
Читтә йөрдем яманлыктан,
Күпне күрдем бу тормышта.

Узмышлар юк язмышлардан,
Сакла, Ходам, каргышлардан.
Аерма тик дус-ишләрдән,
Ташлама тик ялгызлыкка.
Ә мин сиңа дога кылам,
Сүзем туры — вәгъдә-иман!

## *Көзге этюд*

Җиргә иңде кабат көзләр,
Йөрәк әрни нигәдер.
Көзге яңгыр — сагыш җырым —
Күңлем кылын чиртәдер.

Күк томаннар басуларда,
Җәйдән соң шыксыз кыры.
Салкын җил керә куенга,
Җанны өшетә җыры.

Кыр казының моңлы таушы
Яңгырый басу-кырга.
Кайтып барам туган якка,
Сагышны таратырга.

*** * ***

Тауга карап тау булмадым,
Тауларны тик яраттым.
Таудай башны горур тотып
Яшәргә дип җан аттым.

Тауга менеп моңнарымны,
Җырларымны яңгыраттым.
Башкаема сагыш төшсә,
Чатыртауда тараттым.

Бу тормышның авырлыгын
Йөгәнләргә тырыштым.

Әй син, дөнья, гүзәл дөнья,
Сине өзелеп яраттым...

### ***Торналар төшә микән?..***

Дөнья шулай яратылган,
Бездән генә калмаган,
Илле яшьтә барлый һәркем
Кылган эшен яңадан.

Сизелми дә еллар узган,
Чәчләргә чалы кунган.
Маңгаемда тирән сырлар...
Бездән соң ниләр калган?

Шөкер, бушка яшәлмәгән,
Бездән соң үсми кылган.
Без утырткан бакчаларда
Алмалар пешеп тулган.

Авыр булса да заманы,
Нигезен салдык корычтан.
Авыл кордык, юллар суздык,
Мәктәп салдык берочтан.

Кырлары, шөкер, чәчелгән.
Араннар тулы терлек.
Үз көнен үзе күрә ич,
Илбәктә* яши хөрлек.

Язларында күлләренә
Торналар төшә микән?..
Яшь гомерләр узган төбәк
Һаман да истә икән.

### ***Хәтер барлый...***

Мин тауларда булдым, хозурландым.
Түбәләре тигән болытка.
Кыяларга бәрелеп, кайтавазым
Яңгырады җитеп офыкка.

Мин таулардан затлы чаңгыларда
Кошлар кебек очтым түбәнгә.
Булдым затлы кунакханәсендә,
Төн үткәрдем люкс бүлмәдә.

Авыз иттем татлы ак шәрабын,
Тау халкының алдым сәламен.
Ләкин күңел очты туган якка,
Кендек каны тамган туфракка.

Кавказлардан гүзәл Чатыртавым,
Анда калды малай чакларым.
Хәтеремә төште кизитектән
Гади чаңгыларда чапканым.

Хәтеремә килде Мәчет тавы*,
Киң кырлары туган якларның.
Онытсак та кайчак, хәтер барлый
Туган якны, малай чакларны...

## *Бисмилласыз малайлар*

Кызыкмыйм мин мәрмәр сарайларга,
Исем китми яңа байларга.
Күңелем затлы сүзгә сусаганда,
Мин авылга кайтам, бабайга.

Заманага бабай бәя бирә.
Ә бәһасе аның үзенчә:
«Без күргәнне, улым, балаларга
Язмасын, — ди, — иде күрергә».

Бабай сөйли, барлый үткәннәрне,
Ходай биргән аңа хәтерне.
Калдырасы килә оныгына
Үзе үткән данлы дәверне.

Мин еш кына сүгәм заманасын,
Тетеп ташлыйм илнең хуҗасын.
Бабай гына көлемсерәп куя:
«Күрмәдегез дөнья нужасын».

Яше инде аның сиксән биштә.
Гәзит укый әле күзлексез.
Язмышына шөкрана итә,
Ходаема — дога, өзлексез.

Ике сугыш узган язмышында,
Малай чактан нужа күргән ул.
Ачлык елның салкын кыш көнендә
Дүрт туганын җиргә күмгән ул.

Язмышына бүген рәхмәт укый.
«Яшисез, — ди, — балам, бәхеттә».
Биш намазын бер көн калдырмыйча,
Җомга саен бара мәчеткә.
Ул сөйләгән бик күп хикәятне
Аңламыйча ләкин тыңлыйбыз.
Алабута ашы, кәлҗемәне
Белә микән бүген кайсыбыз?

Яратмый тик бабай ялкауларны,
Арт басуны көн дә урый ул.
Сусаганда тулган арышлары,
Дога укып, яңгыр сорый ул.

Нигъмәт тулы бүген өстәлләрдә,
Зарланабыз һаман тормышка.
Икмәк сайлый халык кибетләрдә,
Күпләр ләкин баткан бурычка.

Күпме гыйбрәт ята тарихларда,
Күпме гыйлем сыйган картларга!
Бу дөньяның ыгы-зыгысында
Кими бара ләкин алар да.

Бәрәкәтнең җирдә беткәненә
Җавап тота бүген бабайлар.
Без бит җиргә бисмилласыз килеп,

Нужа күрми үскән малайлар.

## *Кайтыгыз, онытмагыз**

*(Җыр)*

Туган яктан киткәнемә
Инде күп язлар үткән.
Җитсәм дә гомер көземә,
Яшьлегем чыкмый истән.

Кушымта:

Туган якка, туган йортка
Кайтыгыз, онытмагыз.
Көтә безне туган нигез,
Моңаеп, япа-ялгыз.

Яшәсәк тә чит җирләрдә,
Без бит аңа чит түгел.
Туган йорт ялгыз калганга,
Сызлана, сыкрый күңел.

Кушымта.

Дөньяның мин нинди генә
Юлларын урамадым.
Туган якта көтә сагнып
Балачак урамнарым.

Кушымта.

## *Көзге моң*

Көзге яңгырлар түгелә
Күкләрнең итәгеннән.
Сагышлы моңнар сибелә
Тальянның телләреннән.

Уйна, дустым, гармуныңда,
Уйна туган ягымда,
Яшьли сөеп ятка калган
Җан ярлары хакында.

Тальян күреген сузганда,
Күзләреңә моң тула.
Чишмәдәй чыңлый гармуның,
Җаннарны сызландыра...

Язмыш безне читтә йөртә,
Туган як һаман истә.
Көзләрендә моң-сагыштан
Күңелем сыкрый читтә...

## *Күрешәсе килә*

Әйләнәм дә карыйм елларыма,

Еллар буйлап сузыла юлларым.
Юлда калган күпме борчуларым,
Җирдән киткән күпме дусларым.

Ерак калган наян малай чагым.
Көлемсерәп карый егет чак.
Кызлар кочып йөргән шаян чаклар...
Хатирәләр калган бер кочак.

Дөнья йөген ташлап кайчагында
Шул чакка бер килә кайтасы,
Балачакны авыл урамында
Кочагыма килә аласы.

* * *

Җырларым сыймый залларга,
Заллар да кысан ласа!
Урманнарда йөрим җырлап,
Күңелем сагышланса.

Имәннәрдән көч алам да
Сарылам каеннарга.
Җаным кайчак сызласа да,
Бирешмәм кайгыларга.

Иркен сулап бер җырласам
Кушылып урманыма,
Дөньялыкның шакшысыннан
Җаным шунда арына.

## *Күңелемдә бер теләк...*

Имәннәрең бирде миңа ныклык,
Каеннарың — җанга сабырлык.
Миләшләрнең, усак, юкәләрнең
Серен мәңге алып калырлык.

Синдә калды бәйсез малай чаклар,
Хәтеремдә әнкәй назлары.
Безне көтеп туган ал таңнарның
Яшьлек эзен саклап атканы.

Илһам алам синдә җырларыма,
Мәңге гашыйк иркен кырларга.
Тауларыңның алам горурлыгын,
Дога кылам сиңа юлларда.

Көй язалар миңа чишмәләрең,
Хәтеремдә яшьлек иртәсе.
Балачакның җәйге иртәсендә
Без су алган кое сиртмәсе.

Язмыш бүген читтә йөретсә дә,
Күңелемдә бары теләк бер:
Китәр чакта кабул итсен иде
Үзенеке итеп туган җир.

## *Моң суза күңелдә*

Сары яфрак бураннары
Сагышларны кузгата.
Балачагым урамнары
Күзен хәтергә кайта.

Каплаган күзге офыкны
Чатыртау томаннары.
Җаннарымда кабат бурый
Яшьлегем бураннары.

Чатыртау. Көзге яфрак.
Уйный кырда җил генә.
Күңел түрендә, сузылып,
Яшьлектән бер моң килә.

## *Яңа ел килә*

Һәр Яңа ел бирсен өметләр,
Кызыктырмый мине тәхетләр.
Тынычлыкка җирдә ни җитә?!
Дуслар булса янда — шул җитә!

Гомерләр бит никтер тиз үтә.
Гомеремә Яңа ел килә!
Һәр аткан көн туган җиремдә
Сөенеч бирсен иде илемә!

## *Кайтып килдем*

Яшәсәм дә күптән таш калада,
Җаным ургый язын ташудай.
Хәтер чаба узган гомер аша,
Яшь тай кебек яшел болыннан.

Төшләремдә кайтам авылыма,
Җиң сызганып чыгам басуга,
Орлык сибәм иркен кырларыма,
Дога кылам уңыш булсынга.

Тургайларга кушылам җырларымда,
Ялантәпи йөгерәм чирәмдә.
Таллар гына гүя үпкәләгән,
Егетләре читтә йөргәнгә.

Күзем ачсам — төшем югала.
Кая моңнар, кая син тургай?
Язгы таңда соры кала буйлап
Узып бара җансыз трамвай.

Белмим, кайчан, язмыш сукмаклары
Алып кайтыр туган якларга?
Ә бүген мин төштә булса да
Кайтып килдем туган авылга...

## *Халык җыры*

Җырла, җырла, диләр дуслар миңа
Яңа дәртле көйләр, җырларны.
Ә мин сузам моңлы халкым җырын,
Ул җырларда аның узганы.

Халык җыры кайта гасырлардан,
Саклаганнар аны бабамнар.
Дастаннарны утка яксалар да,
Моңлы җырлар торып калганнар.

«Карурман»ны сузам кайчагында,
Өткәм җыры — узган балачак.
«Каз канаты» теләү җаннарымны,
Гүя әнкәй судан кайткан чак.

Татарымның көчле рухын саклый
Тарихыбыз «Әдрән диңгез»дә.
Моң агыла сәхнәләргә сыймый,
Бар җиһанга гүя сибелә.

Олы юлда калган эзләремне
Сагынамын, салам көйләргә.
Халкым җырын саклый алсак иде
Бездән соң да җиргә килгәнгә.

## ***Моңлану****

*(Җыр)*

Чәчәкләр белән бергә мин
Яшәрәм яз килгәндә.
Күзләрен моңга күмеләм,
Кыр казлары киткәндә.

Кошлар белән минем дә җан
Очамы туган якка,
Балачак калган урамга,
Яшьлегем калган чакка?

Язмышыбыз — кошларныкы.
Язлары бар, кышлары.
Аермасын юлларымнан
Язмышның ялгышлары.

*** * ***

— Нихәл анда — Азнакайда? —
Дип сорыймын очрашканда.
Туганымдай якын күрәм,
Якташларны очратканда.

Бүген читтә яшәсәм дә,
Үткәннәрем калды анда.
Гомеремнең чишмә башы —
Чатыртаулы Азнакайда.

— Азнакай бит туган җирем, —
Дип әйтәсе килә шунда.
Шунда тудым, шунда үстем,

Зиратым да булыр анда.

*** * ***

Язларында туган якка
Кошлар һаман кайта микән?
Күп нәрсәләр онтылса да,
Тәүге сөю кала икән...

Колыннары болыннарда
Уйный-уйный чаба микән?
Йөрәк кенә, яшь тай кебек,
Һаман чаба, чаба икән...

Тургайлары зәңгәр күктә
Моңлы җырын суза микән?
Күпме генә сагынсаң да,
Яшьлек кайтмый, уза икән...

*** * ***

Беркайчан да онытмагыз —
Алда сират күпере.
Әнкәйләр безне кичерер,
Тик Ходай кичерерме?
*Җырдан*

Бәхиллеген алмасак та,
Әнкәй безне кичергәндер.
Без кайтуны көтеп көн дә
Күз нурларын бетергәндер.

Дусларыма телим теләк:
Исән чакта кайту кирәк.
Минем сыман тик үкенеп
Өзелмәсен сезнең йөрәк.

Күпме генә ялварсам да,
Кире кайтмас — әнкәй ерак.
Сагынып ла гомер уза,
Бир сабырлык, түзсен йөрәк.

## *Узмасын гомерләр заяга**

Ходайдан бирелгән гомернең
Еллары йомгактай урала.
Кадерен белмәсәң яшәүнең,
Йомгакның очлары чуала.

Аңласаң гомернең кыйммәтен,
Тормышлар җай гына уза ла.
Тотмасаң кулда нык орчыгын,
Гомер-җеп өзелә уртада.

Көннәрен, сәнгатен, елларын
Кирәктер җентекләп санарга.
Һәр аткан ал таңын язларның
Кадерлик бу фани дөньяда.

Гомер-җеп орчыгын сакларга
Язсын ла бу якты дөньяда.
Орчыктан өзелгән җеп сыман
Гомерләр узмасын заяга.

## *Дуслар кирәк*

Эзләсәң дә, яңа дуслар
Табылмыйлар җир йөзендә.
Була икән дуслар якын,
Сынауларны үтсә генә.

Чын дус була шунда гына —
Авырлыкны бүлә алса,
Кайгы килгән чакта сиңа,
Киң җилкәсен куя алса.

Дуслар кирәк бу дөньяда —
Яман юлдан киткән чакта,
Сугып хәтта яңагыңа,
Туры юлга чыгаралса.

Дуслар кирәк — ялгышыңны
Вакытында күрә алса,
Җанда янган сагышыңны
Кыл урталай бүлеп алса.

Дуслар кирәк — шатлыгыңны
Сөенә-сөенә бүлешкәндә,
Сагынып кайткач туган җирне,
Кочак җәеп күрешкәндә.

## *Кемне көтә?*

Каршы ала кайткан саен
Аргы якның каеннары.
Озак кайтмый торган өчен
Әллә алар кайгырганмы?

Түбән очның инеше дә
Ник саеккан, кибә микән?
Утлар янмый күп өйләрдә, —
Күпләр җирдән киткән икән.

Безнең яшьлек эзләрендә
Бәбкә үлән үскән икән —
Ятим капка төпләрендә
Безне беркем көтми икән.

Мине кемдер көтәдер дип,
И ашыгам каршы ярга.
«Кайттыңмы?» — дип, әнкәй анда
Чыгар кебек каршыларга.
*** * ***

Яхшылыктан яман эшкә
Бу тормышта бер адым.
Нәрсә язганын белергә
Күрәзәче булмадым.

Җирдә кылган изгелеккә
Ходай бирә савабын.
Яман эшкә туры килә
Тотарга бер җавабын.

Гомернең уза еллары,
Барсына хуҗа Хода.
Изге булдым дип әйталмам,
Булгандыр гөнаһы да...

*** * ***

Дусларымнан күтеп алкыш,
Яшимен янып-көеп.
Язмышлардан юк шул узмыш,
Сагыш та уза тиеп.

Яшьлек калса да үткәндә,
Картлык әле читтәрәк.
Гомер атым тышауларга,
Беләм, әле иртәрәк.

Чапсын әле гомер атым,
Күңел һаман җилбәзәк.
Үкенергә тик язмасын,
Гомер көзенә җитәрәк.

Яшьлек иле атавында
Калса да ялгышларым,
Тирбәләм язмыш салында...
И гомер агышлары...

# Күңелдәге уйлар

Яхшылык эшлә дә суга сал!
Халык күрмәсә, балык күрер...
*Халык мәкале*

## *Гөлләр чәчәм*

Еллар йолкый гомер календарен,
Калыная акыл биштәре.
Көзге яфрак кебек оча еллар,
Узган еллар — кылган эшләрем.

Гомер агачыннан орлык төште,
Туган җирдә бирде үсенте.
Юлларымда гөлләр шытты микән,
Кычыткanмы каплый эземне?

Бу дөньялар шулай яратылган,
Сынаулардан тора гомерләр.
Күрсәм диеп татлы җимешләрен,
Гомер бакчамда чәчәм гөлләр.

## ***Сезгә бирәм***

Күзге җилдә бөтерелеп,
Яфрак кебек җаным очты.
Йөрәгемне ялгызлыкның
Чукып алды яман кошы.

Аз булмады моң-зарларым,
Егылмыйча җирдә калдым.
Сез булганга, дускайларым,
Кайгыларны җиңә алдым.

Сез булганда, җанкайларым,
Онытыла борчуларым.
Булган чакта тәндә җаным,
Сезгә бирәм күңел җылым.

## ***Үкенмәм***

Булган байлар, токкан ялчы.
Затлы пулат, таш сыннары.
Онытса да патшаларны,
Халкым саклый дастаннарны.

Яшим җирдә җиткәненчә,
Ходай риза кылганыма.
Байлыкларга табынмыйча,
Шөкер кылам булганына.

Шигырьләрем — күңел серем,
Сезгә ачам йөрәк эчем.
Укысалар оныкларым,
Бәхет булыр минем өчен.

Бәхетлемен, яшәгәндә
Файдам тисә бүтәннәргә.
Үкенмәмен үткәннәргә,
Матур итеп озатсалар
Бу дөньядан киткән мәлдә.

## ***Түләрмен кебек бурычны...***

Әнкәй безгә тәүге сулыш өрде,
Биләүләргә безне ул төрде.
Китап сөйде әнкәй, Китап белән
Тәрбияләп безне үстерде*.

Кырыс иде әткәй, акыл биреп
Әйтә иде сүзен күп чакта.
«Кыл яхшылык, балам, дөньялыкта» —
Дигән сүзе тора колакта.

Урыйм ул утырткан урманнарны**,
Каеннары буйга үрләгән.
Имәннәрнең горур ябалдашы

Урманнарның иңен иңләгән.

Аз яшәде алар дөньялыкта,
Кыска булды гомре аларның.
Алар сүзе булды таянычым,
Әгәр килсә авыр чакларым.

Алар сүзе булды миңа сабак,
Егылганда киңәш бирүче.
Ялгышканда, тартып итәгемнән,
Дөрес юлга алып керүче.

Киткәннәргә бурыч түләп булмый,
Йокласыннар иде тынычлап.
Исәннәргә кылсам яхшылыклар,
Түләнгәндәй булыр бурычлар.

*** * ***

Гомерләрне кыска диеп
Юрамыйм әле һич тә.
Яшим язган гомеремне,
Сөенеп һәрбер кичкә.

Язмышыма язылганын
Яшим куанып кына.
Риза булып булганына,
Догамны укып кына.

Шатлыгы да, хәсрәте дә
Ходайдан безгә иңә.
Оҗмахлар да алыштырмас
Якты дөньяны җирдә.

## *Аерма*

Ак җәймәле ак кышларым,
Җәйдә калды аккошларым.
Саф күңелле җан дусларым,
Ташламасын чын дусларым.

Тормыш юлы искитмәле,
Күп чакларда сикәлтәле.
Чоңгыллары көтеп тора,
Урау юлны дустан сора.

Авыр чакта сузсаң дуска
Ике кулың, кирәк булса,
Иртәгәсен килер янга
Ул да сиңа авыр чакта.

«Мин!» дигәннәр бик еш кына
Ялгыз кала бу тормышта.
Сакла, Ходам, ялгышлардан,
Аерма тик чын дуслардан!

## *Әгәр әйтсәләр...*

Исем китми хөсетләргә, көнчеләргә,
Тисен димен файдам җирдә кешеләргә.
Яшим үссен диеп бакча эзләремдә,
Куанычы булыр димен күзләремдә.

Сөенсеннәр иде җирдә оныклар да,
Елмайсыннар күңелләре боеклар да,
Сөю тапсын иде җаны ялгызлар да,
Җырласыннар көйсезләр һәм моңсызлар да.

Күңел моңын салам бүген җырларыма,
Игелек кылу бары минем уйларымда.
Дога белән чыгам йөргән юлларыма,
Миңа язган язмышымның елларында.

Янсын әйдә хаксызларның керле җаны,
Сөенсеннәр дусның җанга якыннары.
Бәхет булыр, әгәр әйтсәләр кешеләр:
«Үзеннән соң калдырды, — дип, — олы эшләр».

## *Көзге уй*

Көзге яңгыр, тишелгәнме
Әллә күкнең гөмбәзе?
Туктаусыз тамчы коела,
Шаулый калай түбәсе.

Чиртә гүя думбрага
Моңсулы серле тавыш.
Көзге җил сугылган чакта,
Көчәя кенә сагыш.

Җанымны кисә ялгызлык,
Тәрәздә караңгылык.
Шомлы уйлар арасында
Йөрим кайчак каңгырып.

Уйларымны ишеткәндәй
Узып бара бер егет,
Сукранып язмышыннан,
Бөтен дөньясын сүгеп.

Таратты шыксыз уйларны,
Шомлы булса да киче.
Миндә генә түгел, ахры,
Ялгыз аккошлар хисе.

## *Җаным чиста*

Белмәсәм дә яттан догаларны,
Күңелемдә ята чисталык.
Изге азан иңли дөньяларны,
Иртәгәсен уйлый бар халык.

Мәчетләрдә яңгрый изге азан,
Кол Шәрифтә татар намазда.
Күпме фикер, зыялы сүз ята

Мөфти сөйли торган вәгазьдә!

Хәтер барлый халкым кичкән юлны,
Күңелемдә тарих тузаны.
Еллар аша килә ни сузылып?
Халкымныңмы авыр узганы?!

Яхшылыкка җирдә омтылдым мин,
Җаным чиста. Ансын әйталам.
Ярлыкачы, диеп, дога кылам,
Ялгышларым булса, йа Ходам!!!

## *Кайтыр идем, әнкәй**

*(Җыр)*

Көтмәгәндә киттең, әнкәй,
Ялгыз калдым аерылып.
Синнән башка ятим яшим,
Канатларым каерылып.

Кушымта:

Язмышыма язган яшәү
Сагынып газиз кешемне.
Кайтыр идем яннарыңа
Ташлап бөтен эшемне.

Кайтыр диеп көткәнсеңдер,
Күзләреңне талдырып.
Кайталмадым, ни хәл итим,
Киттең ятим калдырып.

Кушымта.

Исән чакта белмәгәнбез
Әнкәйнең кадерләрен.
Искә төшеп, төшкә кереп,
Өзелә бәгырьләрем.

Кушымта.

## *Ташлама тик...*

Язмыш сукмаклары борма-борма,
Йөртә безне урап-урап та.
Күтәрә ул шөһрәт тауларына,
Кайчак сала китереп пычракка!

Язмыш елгалары дулкынлана,
Илтеп ташлый кайчак тынлыкка.
Басма салам барыр юлларыма,
Күпер корам — калсын оныкка.

Язмыш җилләренә ияртә дә
Суккаларга мине ашыга.
Давыллары юлдан кире бора,
Кар-бураны чыга каршыга.

Зарлануым түгел язмышыма,

Әллә давыл, әллә таш ява,
Авырлыгын мин җиңәргә әзер,
Рәхмәтеңнән, Ходам, ташлама!

### *Минем еллар*

«Минем еллар — минем байлыгым», — дип,
Вахтанг* җырлый кушып бар моңын.
Гомер узган саен мин дә барлыйм
Елларымның һәрбер адымын.

Минем еллар — минем сагышларым,
Әткәй-әнкәемнән алган моң.
Күпме борчу сезгә салганымны
Үзем әти булгач аңладым.

Минем еллар — минем табышларым,
Улым туган көннәр шатлыгы.
Исмем яши илдә, димәк, тагы
Җирдә кала нәсел дәвамы.

Минем еллар — гомерем китабы,
Һәрбер бите — язмыш язганы.
Үкенерлек түгел узганнары,
Имин булса иде калганы...

### *Шигърият*

Хис ташкыны кайный канда.
Шигърият ул — сихри дәрья.
Җыр-моңнарым сыймый җанга,
И гаҗәеп шигъри дөнья.

Шигърият — серле кораб,
Еракларга китә алып,
Уйларымның давыллары
Сагышларга кайчак салып.

Очкын сала йөрәкләргә,
Өмет бирә көткәннәргә,
Сулыш өрә җаннарына
Хәсрәтеннән көйгәннәргә.

Шигърият ул — изге дөнья,
Сүзем калса иде шунда...

### *Тапсын*

Адәмне сулга язмышта
Йөртә, диләр, шайтаны.
Күрмәгән тик беркем аны,
Бар да Алла язганы.

Дөрес юлда йөресәң дә,

Гомерләр уза китә.
Шул гомердә кеше бары
Яхшылык кылмый нигә?

Телим тынычлык илемә,
Дуска — шатлык-куаныч.
Дошманнар да этлегеннән
Тапсын үзенә юаныч.

### *Сабыр гына*

Җәйләрдә ачы булса да,
Көзен баллана балан.
Шундый безнең язмышлар да,
Тормый ал белән актан.

Тормыш тукмый бик еш кына,
Салып сандалларына.
Ходай биргән сынауларны
Узамын сабыр гына.

Сызламасын димен күңел
Гомеремнең көзендә.
Кылмый яшәргә тырышам
Яманлык җир йөзендә.

### *Дусларның чын дигәне...*

Дисәләр дә: «Без бу җирдә
Язмышның колы бары», —
Куркытмый мине тормышның
Җилләре, давыллары.

Яшим җирдә үземнән соң
Калсын диеп гөлләре.
Соклансыннар карап җирдә
Бездән калган эшләрне.

Язмышларның кайвакытта
Исә ачы җилләре.
Кайберәүләр ялгыз кала,
Көтә салкын чәйләре...

Үтәләр гомер җәйләре,
Килә гомер көзләре.
Яннарымда калсын иде
Дусларның чын дигәне...

### *Яхшы сүз*

Кемдер килә, кемдер китә,
Бу дөньяга ни җитә!
Килмәгән беркем мәңгегә —
Ике карыш җир көтә.

Җирдә ничек яшәсәк тә,
Гомерләр үтә китә...
Яманлык кылмыйк бу җирдә,
Бергәлеккә ни җитә!

Хезмәтләрең җимеш бирсә,
Анда хөрмәте көтә.
Чәчкә көмеш йөгертсә дә,
Яхшы сүз җан эретә.

Айлар үтә, еллар үтә,
Алда мине ни көтә?
Атасы таң, туасы көн
Йөрәгемне җилкетә.

## *Кем ышанмый...*

Гомер елгасы ярында
Калган күпме манзара.
Кыя таштай авырлыкны
Салдым кайчак аркама.

Яшьлек кәйләсе белән мин
Ваттым каты ташын да.
Хәйләсен кайчакта тойдым
Читләрнең карашында.

Ялганнарны урап уздым,
Егылмыйча упкынга.
Торып калган чак та булды
Җиде юлның чатында.

Күңелем чиста, юк карасы,
Бары еллар ярасы.
Кем ышанмый — йөрәгемне,
Мөмкин, ачып карасын.

## *Юбилейдан соң*

*(Ә.Атнабаевка ияреп)*

Имештер, мин Дәү Советның
Акыллы бер кешесе,
Бүген һәйкәл бастырырлык
Хөкүмәт эшлеклесе.

Бар халык үлеп яраткан
Мин икән бит затлы зат.
Яхшы законнар язганмын,
Менә дигән депутат!

Минем кебек бөек шагыйрь
Әле, диләр, булмаган.
Моңлы җырчы әле миндәй
Бу дөньяда тумаган.

Мин ясаган сурәтләрне*
Музейларга элерләр.
Исемемне тиздән инде
Тирә-якта белерләр.

Имештер лә миндәй кеше
Гасырга килми ике.
Тарихка язып куярлар
Җирдә мин кылган эшне.

Җырчылар миңа багышлап
Кич буе җырладылар.
Биючеләр күзен кысты,
Оялып тормадылар.
Хатын хәтта аптыраашта,
Миңа карап шакката.
Нинди шәп ир икәнмен бит
Ул янымда юк чакта.

Әй сөйлиләр матур сүзләр,
Чәчәк бүләк итәләр.
Моңсу гына уйлап куйдым:
Мин киткәч, ни эшләрләр?

Юбилейлар килә-китә.
Котылсам да аңардан,
Айнып булмый юбилейда
Әйтелгән мактаулардан.

## ***Бер дусны уйлап***

Табигатьтә җиткән көзләр,
Яфрак ява, гөл сула.
Гомер уза, килә беркөн
Көз адәм баласына.

Ул сызлана, моңсулана.
Әллә җәе булмаган?
Гомеренең язларында
Игелекләр кылмаган?

Әллә язмыш сукмаклары
Урап узган бәхетен?
Салкын бәреп тора, гүя
Боздан корган тәхетен...

Аның җаны сызлаганга,
Минем дә йөрәк туңа.
Киләчәкне уйлап куям
Шулчак шомланып кына...

## ***Ходай белә...***

Кайгыларның минем башка
Ниндие генә төшмәсен,
Хәсрәтемне җиңеләйтеп,
Беләм кемнәр бүлешәсен.

Бакыйлыкка киткән чакта,
Күреп сулышым сүнәсен,
Соңгы йотым суны миңа
Беләм кемнең китерәсен.

Яшим шуңа дусларымның
Кадерләрен белеп кенә.
Кемне кемнәр озатасын
Бер Ходаем үзе белә...

### *Үтенеч*

Адәмнәрне боза дан-шөһрәте,
Харап булды шуннан күпме ир!
Сакла, Ходам, берүк иярмәсен
Бу гомердә миңа яман чир.

### *Арала син мине сагыштан…*

Язмыштан юк, диләр, узмышлар,
Язмышларны боза ялгышлар.
Тормышта булса да сагышлар,
Һәр көне китерә табышлар.

Ходайдан язылган язмышлар,
Яшик без алмыйча каргышлар.
Хезмәтем китерсен шатлыклар,
Читтәрәк йөрсеннәр сагышлар.

Ходаем, сакла Син ялгыштан,
Көч алам һәр туган таңымнан.
Сакладың Син мине тумыштан,
Арала бүген дә сагыштан!

*** * ***

Хәмер упкыны йотты
Күпме зыялы затны.
Күтәргәч шәраб бокалын,
Уйларым кулдан тотты.

### *Дус һәм дошман*

Рәхмәт укыйм кайчак дошманыма,
Бу дөньяга күзне ачканга.
Аңлый алмыйм кайчак дусларымны,
Кирәк чакта ташлап качканга.

Дус дигәннәр карый үз җайларын,
Сүзнең сөйли кулаен үзенә.
Дошман дигән һәрчак уйлаганын
Туры бәреп әйтә йөзеңә.

### *Юк, эзләмим...*

Тәкъдиремә әллә язылганмы:
Якын алам читләрнең зарын.

Кайгылары кисә җаннарымны,
Йөрәгемне телә газаплары.

Гомер буе тыңлыйм гозерләрен,
Җавап ала, шөкер, күбесе.
Чарасызлык җиңә теләкләрне,
Үтәлмичә кала кайберсе...

Язганына түгел зарлануым,
Авыр булса булсын камытым.
Мин эзләмим җирдә башка юлны,
Ялгыз калдырмасын язмышым.

## *Сәясәтче була алмам*

Сәясәтче булмам, ахры,
Эзли белмим урау юлны.
Барган юлым булды туры,
Җаным моң, хис белән тулы.

Сәясәтче булмам, ахры,
Түгелдер ул минем тәхет.
Эзем калса туган җирдә,
Минем өчен булыр бәхет.

Сөйли белмим купшы сүзне,
Сәясәтче, ахры, булмам.
Мин канәгать — гади сүздә
Хисләремне җиткералсам...

## *Янды гомер*

Сынады язмыш, сынады,
Сыгылмаска өйрәтте.
Җаным янган чакларымда
Тәмәкене көйрәттем.

Күмер кебек янды гомер,
Көл булмаска көч таптым.
Төпчегенә кадәр тартып,
Туңган җанны җылыттым.

Эткәндә дә арттан мәкер,
Егылмаска тырыштым.
Түземлек юмарт сыйлады,
Җыям хәзер уңышын...
*** * ***

Язлар килде кабат шәһәремә,
Тәрәзәгә бага күзләрем.
Очар кошлар кебек канат куеп,
Җилкендерә кабат күкләрем.

Җаным тарта күксел басуларга.
Бозлар аккан алкын суларга.
Йөрәк ярсып тибә ташкын судай,
Күкрәгемнән теләп чыгарга.

Умырзая кебек, яз килгәндә,
Килә янып нурлар сибәсем.
Җырларымда тургай моңы булып
Ялгызларга барып керәсем.

Сагышларын алып ялгызларның
Һәм эретеп күңел бозларын,
Алып килсен иде яңа язлар
Күптән көткән сөю назларын.

## ***Сезнең белән яшим***

Көткәнсеңдер, әнкәй, кайталмадым,
Читтә йөртте язмыш-юлларым.
Сиңа атап җырым язылмады.
Ялгышымны соңрак аңладым.

Гомер узды, нишлим, чит якларда,
Дөнья кудык җигелеп заманга.
Бәхиллегең сорап калалмадым,
Үкенеп яшим шуңа һаман да.

Еллар үткәч, ахры, акыл иңә,
Син керәсең бик еш төшләргә.
Сагышларым тия йөрәгемә,
Хәтер кайта кире үткәнгә...

Каршы ала мине, әнкәм кебек,
Өй каршында үскән miләшем.
Яшим, әнкәй, бүген сине сагнып,
Әткәй, тотып синең киңәшең.

Еш кайтамын бүген туган якка,
Сугылмыйча китмим зиратка.
Буш нигезнең утсыз тәрзәләре
Синсез генә, әнкәй, озата.

## ***Туган як дәвасы***

Яхшылыкны алам дусларымнан,
Яманлыктан качам тормышта.
Акыл җыям үткән елларымнан,
Сабак алам кылган ялгыштан.

Арынасым килә сагышлардан,
Кулга алам дустым гармунны.
Моң түгелә гармун бәгыреннән,
Сагыш кына телә җанымны.

Дәва эзләп, күңел сызланганда,
Туган якларыма юл чыгам.
Хәлсезләнгән бөркет баласыдай,
Бусагама кайтып егылам.

Һавасы да үзгә туган җирнең,
Җанга сихәт һәрчак ул бирә!
Чишмәсенең салкын сулары да

Тәннәремә кодрәт иңдерә.

Имәннәрен кайтып бер кочсам да,
Гайрәт тула кебек каныма.
Тургайлары шашып сайраганда,
Моңнар алам яңа җырыма.

Киң күңелле авыл, әнкәйләрдәй
Суза кулын, әгәр егылсаң.
Кичерер дә димә, әткәйләрдәй
Кырыс та ул — яман эш кылсаң.

## *Бүген язам*

«Каләм алдың кулга соңлап кына,
Ник язмадың элегрәк?» — дисез.
Шигырьләрем минем күңелемдә
Күптән туганлыгын белмисез.

Заманасы авыр булса булды,
Авыл кордым — калды халкыма.
Таш түшәдем авыл юлларына,
Мәктәп салдым — телем калсынга.

Орлык чәчтем җиргә, дога укып,
Шытымнарын көттем язларда.
Без утырткан бакчаларда бүген
Алмалары пешеп баллана.

Чабышкылар чапты Сабантуйда,
Бәйрәм итте дуслар, туганнар.
Туйлар узды гөрләп авылымда,
Аваз бирде җиргә оланнар.

Авылларга яман чорлар килде,
Базар йота, авыл тезләнә.
Шуны күреп йөрәк өзгәләнә,
Бүген язам җаным көйгәнгә.

## *Яратам мин бу дөньяны*

Яратам мин бу дөньяны,
Мәшәкатьтән торса да,
Замананың сынавына
Көчем җитмәс булса да.

Яратам, җаным кайчакта
Борчуга юлыкса да,
Язмыш аты юлларымда
Чыгымчаклап куйса да.

Сыныйсы килә дусларны,
Авырлык килсә миңа.
Дөнья үзе сыный дусны —
Төшә йомышы синә.

Сакламыйм ачу дошманга,
Эчемдә ут янса да.
Көләм кыен булганда да,

Елардай чак булса да.

Сокланам мин матурлыкка,
Чәчләргә чал кунса да.
Яратам мин бу дөньяны,
Мәшәкатьтән торса да.

*** * ***

Халкым өчен язам җырларымны,
Йөрәгемнән чыга моңнарым.
Көн дә тыңлыйм кеше моң-зарын мин,
Тик әйталмыйм чыгу юлларын...

Илем диеп кылам эшләремне,
Халкым диеп һаман тырышам.
Эзем калсын диеп җирдә яшим,
Ямь табарга телим тормыштан.

Офыкларга ташлыйм карашымны,
Болытлардай ага язмышым.
Оныкларга акыл бирә-бирә,
Киләчәккә китеп барышым.

*** * ***

Үткәннәрдә хәтер йөри,
Әллә яшьлекне эзләп?
Җанны телеп сорнай көйли,
Узган гомерне күзләп.

Еллар уза бер-бер артлы,
Уза бәхетләр эзләп.
Җирдә җырларым калырмы,
Гомер юлымны бизәп?

Гомер үтә, җитә көзләр,
Яши күңлемдә теләк:
Җаным очкач, әйтмәсеннәр,
Бетте, дип, соры бөҗәк.
*** * ***

Каләмкәем, рәхмәт укыйм сиңа,
Уйларымны минем тыңлаганга,
Моңнарымны салып җырларыма,
Бу дөньяга кабат чыгарганга.

Аһ-зарларым әгәр калса җанда,
Сулар өчен һава җитмәс иде.
Уйларымнан күңелем тулышканда,
Йөрәккәем, бәлки, түзмәс иде.

Яз, каләмем, әле җаным барда,
Ач дөньяның кара япмасын.
Күңел җырым җирдән киткән чакта,
Бакыйлыкка мине озата барсын!

*** * ***

Тал егетнең керфегенә
Энҗе бизәк эленгән.
Сагышлармы күңелендә? —
Сихри моңнар сибелгән.

Зирекләрнең колагында
Җемелди алкалары.
Моңсуланып тал озата
Салкын кышка аларны.

Табигатьнең кодрәтенә,
Күрсәң, хәйран калырлык.
Язмышлар йөртә безне дә,
Ходай, бир тик сабырлык.

Таң атканчы елга аша
Кыш бабай салган күпер.
Яшьлек калган урам аша,
Узган да киткән гомер.

## ***Шулай яратылган дөнья...***

Шулай яратылган дөнья,
Гасырлардан шулай килә —
Урын өчен бу җиһанда
Көрәшергә туры килә.

Шулай яратылган дөнья —
Киртәләре чыгып тора.
Кемдер синең юлларыңа
Көтмәгәндә тозак кора.

Шулай яратылган дөнья —
Көнче, хөсете җитәрлек.
Кемдер нигә яман уйда?
Кайчакта исең китәрлек!

Шулай яратылган дөнья...
Дөнья тулы кан-кардәшләр.
Узар өчен гомерләрне
Кирәк тугры фикердәшләр.

## ***Гафу сорыйм***

Ходаемнан гафу сорыйм,
Киткән булсам ялгыш юлдан.
Булмаса да яман уем,
Узып булмый язмышлардан.

Дусларымнан гафу сорыйм,
Үзем белми хата кылсам.
Килсә килсен миңа кыен,
Ышаныгыз, сезне сатмам.

Туганымнан гафу сорыйм,
Вакыт җитми хәл белергә.
Ярдәм кирәк булса, минем
Түрем ачык сез килүгә.

Сөйгәнемнән гафу сорыйм,
Чибәрләргә күз төшерсәм.
Матурлыктан әле беркем
Бу дөньяда ваз кичмәгән.

Вөжданымнан гафу сорыйм,
Гөнаһ кылсам кайчагында.
Каным белән мин түләрмен,
Әле җаным бар чагында.

Гафу сорыйм...

## ***Гомер эзе***

Гомер узган икән, диеп,
Картлар куя уфтанып.
Кайда калган, дип, яшьлегем,
Күпләр йөри моңланып.

Көн-таң атса дөнья куып,
Туктамыйча чабабыз.
Гомер күзе җиткәч килеп,
Аптыраншта калабыз.

Башкаларның ялгышларын
Бу тормышта күрәбез.
Ялгыз калганнар халәтен
Нигә күрми үтәбез?

Җирдә эзе калсын өчен
Килгән һәркем, беләбез.
Якыннарның кайчак җанын
Чыра кебек теләбез.

Ник гомерләрнең үткәнен
Вакытында сизмибез?
Якты дөньяның кыйммәтен
Соңлап кына шәйлибез.

Үкенерлек һич булмасын
Гомерләрнең азагы.
Бакыйлыкта көтмәсен лә
Кыямәтнең газабы.

*** * ***

Дөреслек эзләп барганда,
Яманлыкка тарыдым.
Язмышның урау юлында
Кайчагында абындым.

Изге эшләр күп кылсам да,
Һәрчак рәхмәт алмадым.
Аңлый алмасам да шуны,
Юлда туктап калмадым.

Гомер узган саен, мин дә
Тормыштан акыл җыям.
Йөрәк кайчак әрнесә дә,
Ачык алдагы кыйблам.

# Авылым моңы

*Үзем читтә сине уйласам да,*
*Чарасызлык телә җанымны.*
*Миннән торса авыл язмышлары,*
*Бирер идем газиз җанымны!*

## ***Урыйсы килә кырларны***

Геннарда, ахры, язылган
Барырга кайсы юлдан:
Сәясәтче булыргамы,
Ямь табаргамы кырдан?

Тынычлык юк бүген җанда,
Яшимен ят калада.
Очар коштай канатланып,
Оча күңелем далада!

Сәясәт бәйли кулымны,
Ябышкак сыргак сыман.
Күңелемне богауларда
Тоткан бер тозак сыман.

Өзеп ташлап богауларны,
Кырга килә чыгасым,
Кушылып бүз тургайларга,
Кырлар җырын җырласым!

## ***Китеп барышлый...***

Басуларда әле ак ямаулар,
Ызан буйларында кар ята.
Уҗымнары яшел ашъяулыктай,
Зур уңышка өмет уята.

Ак каеннар йөзен агартканнар,
Усаклары кием алыша.
Буразнада саркый кар сулары,
Кар астына гөрләп су төшә.

Авылымның киң күңеле кебек,
Буалары тулган су белән.
Гөрләвекләр күчә инешләргә,
Ашыгалар көмеш челтерәп.

Лапасларда мөгри сыерлары,
Абзарыннан чыгар җай эзләп.
Усал кәҗә генә су буенда
Тешен чарлый, таллар каезлап.

Тавыклары җырлый яз көенә,
Көяз этәч җирдә казына.
Канатларын шапылдатып куеп,
Тавыш бирә ата каз гына.

Һәммәсе дә якын, гел хәтердә,
Юксындыра читтә чагында.
Тормыш нигә адәм балаларын
Читтә йөртә туган ягыннан?..

Тагын килде язлар авылыма,
Кабатлана сагыну-сагышым.
Түземлекләр теләп авылыма,
Шәһәремә китеп барышым.

### *Кайту...*

Еллар узгач сиңа кайттым,
Туган авылым — җанга дәвам.
Сагынуга сагыш кунган,
Яшьлек инде ерак калган.

Һәммә нәрсә монда якын —
Мәчет тавы, аръяк урам,
Монда тамган кендек каным,
Балачакның эзе калган.

Бакчадагы шомырт исе,
Тәүге тапкыр үптем сине.
Яшьлегемдә шушы кичне
Гүя миңа гайрәт иңде.

Синең өчен ул чакларда
Күпме борын канагандыр?
Аулак өйләр, айлы кичләр
Мәңге истә калганнардыр.

Кайттым гүя егет чакка,
Шул караңгы тыкрыкка.
Синең өчен элеккечә
Сугышасы килеп китте,
Кайтып кабат үсмер чакка.

Су буйларын мин урадым,
Талларым тик танымады.
«Нигә читтә йөрисез?» — дип,
Йорт капкасы сыкранды.

### *Сулыш өрик*

Ачлык кырды авыл балаларын,
Тиф чирүе кисте тамырдан.
Сугыш йотты күпме ир-егетен,
Тик булмады авыл камырдан.

Җыйнадылар бергә мал-туарын,
Ил өстеннән чирү үткәндәй,
Кулак диеп читкә сөрсәләр дә,
Егылмады авыл, чүксә дә.

Крестьян, мескен, бил бөксә дә
Хезмәт көне өчен таякка,
Бөгелмәде, тезләнмәде авыл,
Барыбер торып басты аякка.

Чыдамлыгы аның көчле иде.
Инде яшәп кала алырмы?
Күтәрәмгә калып бара авыл,
Күтәрергә кирәк авылны!

## *Атлар җиктек*

Җигә белмәү малайчакта атны
Булдыксызлык булып саналды.
Хәтерлимен камыт бауларын
Үрелеп тарткан бала чагымны.

Тәртәләргә без тайларны керттек,
Иярләргә мендек үрмәләп.
Өзәңгегә басып атлар көттек,
Зур үсәргә булды гел теләк.

Хәтеремдә әл дә әткәй сүзе,
Ат җиккәндә һаман көйләде:
«Заманалар авыр — юл үтәргә,
Дуслар кирәк дөнья көтәргә.

Җиккән атың юлда армас дисәң,
Солың булсын һәрчак чанаңда.
Ярты юлда ялгыз калмам дисәң,
Ышаныр дус булсын яныңда».

Язмыш безне бик тиз йөгәнләде,
Дилбегәсен бирде кулларга.
Камытын да салды җилкәләргә,
Кушты тормыш йөген сөйрәргә.

Гомер юлы — түгел чана юлы,
Шома гына бармый язганы.
Шатлыгы да, кайгысы да калды,
Беркем белми алда язганны.

Төшләремдә кысам камыт бавын,
Тайларымда чабам болыннан.
Узганнарга гүя йомгак ясап,
Хәтер карый малай чагымнан.

## *Арыш икмәге*

Бу җирдә адәм баласы
Мал-мөлкәткә табына.
Өлгергән арыш көшеле
Якын минем җаныма.

Тук башаклар миңа дәшә,
Әйтерсең алар тере.
Игенченең бөртекләргә
Кушылган ачы тире.

Өлгергән арыш басуын
Кыр кораблары иңли.
Бункерга бөртек агыла,
Энҗе тамчысымыни!

Булмас алтынның кыйммәте,
Күренмәс көмеш бизәк,
Тир түгеп үстергән икмәк
Тормаса табын бизәп!

### *Иң зур байлыгым*

Кайчак дуслар миңа әйтеп куя:
«Озак еллар хуҗа* идең, — дип. —
Бардыр әле шактый чәчү җирең,
Кибетләрең бардыр синең», — дип.

Тартмады шул күңелем сәүдәгә,
Басуларым бүген урылган.
Башка халык бүген уңыш җыя
Мин эшләгән Илбәк** кырыннан.

Матур яши Илбәк һәм үсештә,
Карап туймыйм һәрбер өенә.
Абзарлары тулы мал-туары,
Күңелем бүген шуңа сөенә.

Кайтып керәм аңа үз кешедәй,
Монда бар да якын, үз миңа.
Яше-карты зурлап сәлам бирә,
Моннан да зур бәхет юк миңа.

Колач җәеп һәрчак каршы ала,
Хәер-дога укып озата.
Зур байлыктыр, димен, бу дөньяда
Кайтыр җирең булу җиһанда!

### *Җир газабы...*

Җаны сызлый бүген игенченең,
Теш-тырнагы белән тырмаша.
Заманасы авыр, җитми хәле,
Сөрмәгән җир гүя ыңгыраша.

Ягулыгы кыйммәт икмәгеннән,
Корыч аты тузган, «ябыккан».
Изге җаны гына игенченең
Туган җиргә мәңге ябышкан.

Кайтам да мин чыгам басуларга,
Ә уйларым авыр, газаплы.
Әй җиркәем, нигә түрәләрең
Күрмиләр соң синең газапны?..

*** * ***

Тәү кат керде тырма басуларга,
Буразнада туфрак тарала.
Язга өмет белән чыккан суалчанга
Һөҗүм итә кара каргалар.

Үз калҗасын көткән карчыгадай,
Яңа байлар эзли үз җаен.
Туплый алмый һаман уй-фикерен,

Аптыраштa авыл агае.

Тарихында авыл күпне күрде,
Ачлыгы да аны җиңмәде.
Авыл белән тагын ниләр булыр,
Чит улларга күчсә җирләре?..

### *Авыл мунчасы*

Кергәнем бар затлы сауналарга,
Күргәнем бар төрек мунчасын.
Тик кайсының гына сихәтләре
Авыл мунчасына җитә соң?!

Мәтрүшкәле каен себеркесе
Үткән җәйнең саклый хуш исен.
Мунчадан соң әле озак кына
Һушка килә алмый йөрисең.

Туган якның үлән суларының
Шифасы бар җитмеш чиреңнән.
Мунча пары кайтара яшь чакка,
Инде беттем дигән җиреңнән!

Кайчакларда гәпләшәсе килә,
Җан дусларның җыеп барчасын.
Мунчасында чабынасы килә,
Шәһәр тузаннарын кагасым.

*** * ***

Кул селтим дә шәһәренә,
Кайтам туган җирләремә.
Башым куям чирәменә,
Көч-дәрт алам йөрәгемә.

Бар да таныш миңа монда,
Һәрбер йорты якын җанга.
Якын күреп этләре дә
Сәлам биреп өреп кала.

Сандугачы сайрый таңда,
Сыерлары мөгрәп кала.
Мин — хуҗа, дип, ихатада
Әтәчләре күкрәк кага.

Кайткан саен нигез саныйм,
Йортлар гына кими бара.
Хуҗаларын уйлаганда,
Йөрәгемне сагыш сара.

### *Ядкарь*

Ат караучы Сафиулла абзый
Күченсә дә күптән бакыйга,
Малайчакның матур истәлеге —
Ат сарае торды авылда.

Тайлар көткән җәйге айлы кичләр —
Малайчакның матур ядкаре.

Учакларда көйгән бәрәңгенең
Истә әле һаман тәмнәре.

Тормыш камытын киеп иңебезгә,
Йөгәнләдек яшьтән атларны.
Өзәңгегә буйлар җитмәсә дә,
Без атларга барбер атландык.

Нидер җитми, нидер булган бүген,
Аргы якка карыйм сагаеп.
Балачакның изге хатирәсен —
Сүткәннәр бит атлар сараен.
*** * ***

Кичке авыл тәрзәсенә
Күксел томан сарылган.
Кошлары да тынып калган,
Ай да моңнан саргайган.

Күңлем көзе сагыштанмы,
Нигәдер моңсуланам.
Күзгә йокы керми нигә,
Ятакта боргаланам?

Халәтемне аңлагандай,
Ай да күзләрен йомды.
Авыл урамын уятып,
Эт кенә өреп куйды...

Көзме, синме сәбәпчесе —
Ник күңелем сызлана?
Аңлый алмый һаман шуны,
Җан гына борсалана.

## *Авыл һавасы*

Таш калада җан кысыла,
Булса да ул башкала.
Табынып яшим калада
Авылдагы ташка да.

Бар да җитеш кебек монда,
Җитми җылы җаннарга.
Йөрәгемә дәваларны,
Белмим, каян табарга?

Терелгәндәй кебек булам,
Кайтсам туган якларга.
Бал-майларын алыштыра
Сулар һава да анда!

Кайда йөрсәм, нишләсәм дә,
Күңелдән чыкмый һич тә, —
Авылымда шомырт исе
Яшьлеккә алып китә...

Җаннарыма шифа була
Рәхәт авыл һавасы.

Язмыш кая ташласа да,
Мин бит авыл баласы!

* * *

Җиргә язлар килгән чакта,
Иртәләрен йокым кача.
Ахры, минем тамырларда
Игенчеләр каны ага.

Җан уяна кояш белән,
Кирәк түгел уятучы.
Күңелемнең иң түрендә
Тавыш бирә яз әтәче.

Яшәсәм дә башкалада,
Буразналар күз алдымда.
Язын күңелем кырларымда,
Тургай моңы колагымда.

Әй, авылым, күпме balаң
Яши читтә сине уйлап,
Гомер буе күреп төштә,
Бер күрергә тик зар елап.

## *Соңгы җирлек*

Көзге кырлар өстенә
Күксел томан эленә.
Томан аша кояшның
Ал нурлары түгелә.

Авыл яши уй белән,
Киләчәккә — өметтә.
Тере башаклар шаулавы
Аның күңелен җилкетә.

Авыл яшәсә җирдә,
Дөньяда яшәр телем.
Салмыйк аны сагышка,
Нечкә авыл күңеле.

Сылтап бары заманага,
Ташламыйк авылны без.
Авыл — безнең тәүге бишек
Һәм мәңгелек йортыбыз.

## *Уйлар кайта*

Уйлар кайта язларымда
Кабат туган якларыма.
Уртасына ут кабызып,
Боз агызган чакларыма.

Уйлар кайта кырларыма,
Чәчү чәчкән чорларыма.
Яңгыр көтеп басуларга,
Җан сыкраган чакларыма.

Уйлар кайта авылыма,
Тайлар көткән болыныма.
Гүя озатып кулын болгый,
Әнкәй чыккан юл буена.

Уйлар кайта нигеземә,
Төп йорт кына һаман иңә.
Туган җирдән һаман читтә
Безне генә язмыш йөртә.

Уйлар кайта туган якка.
Мин дә, ахры, уйларыма
Иярермен дә беркөнне
Кайтырмын күк кырларыма.

## *Туган авылым Үчәлле**

*(Җыр)*

Синең иркә кочагыңда
Узган яшьлек елларым.
Сиңа атап бүген читтә
Туа моңлы җырларым.

Кушымта:

Туган авылым, Үчәллем,
Син бит тәүге бишегем.
Балачагым хатирәсе
Кага күңелем ишеген.

Кайткан саен каршы ала
Әткәем каеннары.
Истән чыкмый әнкәемнең
Кул изәп калулары.

Кушымта.

Кырларыңда иген уңа,
Шаулыйлар арышларым.
Киләчәккә өмет баглап
Яши авылдашларым.

Кушымта.

Суы тирән булмаса да,
Җырлап ага инешең.
Ерак юллар аша сиңа
Сагнып кайтып килешем.

Кушымта.

## *Сагынганда*

Җанкаема тынгы тапмаганда,
Тагын кайтам сагнып авылга.
Җил капканың моңсу шыгырдавы
Балачакка гүя кайтара.

Табигатьнең бөтен гүзәллеге
Синдә генә, ахры, җыелган.
Аргы яктан түбән очка таба
Малайчакның эзе сузылган.

Шомыртларның җете аклыгы
Сафландыра кебек күңелне.
Язгы күкнең зәңгәр күлендә
Сызылып кала аккош эзләре.

Тургаеңнан алып моңнарымны
Бер кычкырып килә җырлыйсы.
Ташкаладан кайткач чирәмеңдә
Тәгәрәпләр килә ауныйсы...

## *Декабрь яңгыры*

Табигать тә никтер борсалана,
Фасылларын бутый, ахыры,
Кар көткәндә коеп яңгыр ява!
Соңга калган көзнең яңгыры.

Җир кешесе һаман аптырашта,
Вакытында килсен яз аңа,
Борчыла ул ел фасылын бутап,
Декабрьдә яңгыр яуганга.

Нишләсен соң, түзә инде авыл.
Җир кешесе чыдам — эндәшми.
Йөрәгендә яшен яшьнәсә дә,
Күз яшьләрен безгә өләшми.

## *Ак әбиләр*

Авылларда ак әбиләр
Дога кылып гомер итә.
Сурәтенә карап көн дә,
Кайтмый калган ирен көтә.

Өч малае калды читтә,
Иле өчен көрәшләрдә.
Яше күптән кибеп беткән,
Сабыр гына күзен сөртә.

Килмәсен дип афәт җиргә,
Намазлыкта — гел теләктә.
Дөньялыкка килми калган
Онык кына керә төшкә...

## *Көзге элегия*

Манып, ахры, кояш нурларына,
Көз төшерә җиргә бизәкләр.
Мең төс уйный урман өсләрендә,
Моңсуланып калган тирәкләр.

Көзнең төсе кунган Чатыртауга,
Суырлары уйга чумганнар.
Тау астында җил сурәтен ясап,
Болын буйлап чаба кылганнар.

Басуларда салам күбәләре
Тукталгандай ялга беразга.

Тракторлар, авыр сулап, анда
Камыл ярып сыза буразна.

Чүп ягалар ындыр артларында,
Офыккача җиткән төтене.
Җәйләр белән гүя саубуллашып
Китеп бара казлар төркеме.

Офыкларда, җәйне озаткандай,
Моңсуланып ага болытлар.
Тургай да юк, моңлы сандугач та,
Тынып калган тугай, болыннар.

Җәй үткәнгә гүя сөенгәндәй,
Түбә кыегына тезелеп,
Хуҗа булган кебек дөньясына,
Чыпчыклары шаулый гөр килеп.

Гомер көзең җитә дигән кебек,
Җаннарыма суык җил бәрә.
Хәлләремне минем аңлагандай,
Сары яфрак ялгыз тирбәлә.

### *Көзге рәсем*

Сентябрь. Әбиләр чуагы.
Көзләрнең гүзәл чагы.
Кояш микән соң рәссамы
Җирдә бу манзараның?

Нечкә билле ак каенның
Саргайган затлы шәле,
Таза имән егетенең
Уйларга калган мәле.

Юкәләре дә сагышта —
Коела яфраклары.
Офыкта моңсу тарала
Киек каз тавышлары.

Барча дөнья саргайганда,
Бик тә сәер тоела —
Арыш уҗымында гына
Яшел келәм куера.

### *Хәтер кайта*

Кайтмыйсың дип сорамагыз,
Кузгатмагыз сагышымны.
Кайтмасам да җанда бушлык,
Узып бара салкын кышы.

Авыл гөрләвекләренең
Сулары да, тора чыңлап.
Чылтыраган чишмәләрнең
Йөрер идем моңын тыңлап.

Бар табигать уянганда,
Киләчәкне уйлаганда,
Яшәсәм дә таш калада,
Күңел һаман кырларымда.

Киек кошлар белән бергә
Җаным оча туган якка.
Ярсу язгы ташу булып,
Сыялмыйча ярларына,
Хәтер кайта язларына...

## ***Барыбызның калыр җире***

Авыл көтә һәр баласын,
Китсәләр дә ташлап аны.
Каршылый ул һәр туганны,
Белә үзен юксынганны.

Яшәсә дә чит калада,
Күпләрнең бит күңеле анда, —
Кендек каны тамган җиргә
Кайта кеше сагынганда.

Авыл белә, күрә, түзә.
Кешенең бит бар төрлесе.
Нинди генә булсалар да,
Үз баласы бөтенесе.

Авыл сизгер — барын аңлый,
Белә шундый көн туасын:
Һәр улының нигезенә
Кайтып беркөн егыласын.

*** * ***

Кышкы авыл. Кемдер китә.
Чана уза эз сызып.
Юлчы гына тавыш бирә,
Сихри тынлыкны бозып.

Сирәк кенә моңсуланып
Этләр куялар өреп.
Ялгыз ана балаларын
Һәр кич көтә өзелеп.

Салкын җил йөри тузынып,
Тәрәзләргә сугылып.
Ялгыз ана күңеленнән
Сагыш килә сузылып.

Матчадагы элгеч кенә
Үткәнне хәтерләтә.
Көн дә бер төш күрә ана,
Имеш, бишек тирбәтә.

Күзен ачса, төш югала.
Хәтердән гомер уза.
Тик чикерткә мич артында
Җан сызлатып җыр суза.

## ***Арышларым — сагышларым***

*(Җыр)*

Туган якка кайтып киләм,
Күңелдә сагышларым.
Башын иеп каршы ала
Тулышкан арышларым.

Кушымта:

Арышларым — сагышларым,
Йөртәләр язмышларым.
Сагынуга түзә алмый,
Юлларга чыктым тагын.

Читтә йөргән чакларымда
Юксынам туган ягым.
Сагынам урманнарыңны,
Чәчәкле тугайларың.

Кушымта.

Тургайлар җыры тирбәлә
Җәйге зәңгәр күгендә.
Кайларда гына йөрсәм дә,
Туган ягым күңелдә.
*** * ***

Балачакның серле хатирәсе —
Авыл читендәге алачык.
Тимерченең елгыр чүкеченнән
Аваз сала гүя малай чак.

Ишетелә каеш күрегенең
Уфылдаган таныш тавышы.
Сандалларда әкият тудырып,
Очкыннарның очып барышы.

Учактагы кайнар очкын булып,
Ил-җиһанга без дә сибелдек.
Язмыш утларында иртә янып,
Иртә көеп кемдер сүрелде.

Ә мин, шөкер, әле һаман янам,
Үзгәрерме, белмим, бу заман?
Әллә көтә безне ахырзаман?..
Кемгә калыр, белмим, бу җиһан?

*** * ***

Кышкы иртә, моңсу агачларны
Йолдызлардай сыкы бизәгән.
Энҗеләрме? Суык алкалары
Таллар колагына эленгән.

Тулган ай да әллә өшегәнме?
Салкынлыктан, башка сәбәптән?
Тын офыкта кояш бәргәләнә,
Соңаргандай чыгар сәгатьтән.

Инештәге бозлар чатнаганы
Бозып куя кайчак тынлыкны.
Кое чылбырының чылтыравы
Уяткандай була авылны.

Аргы яктан түбән очка таба
Чана эзе калган сузылып.
Гомерләрнең кышкы юлларында
Яшьлек кенә чаба тузынып,
Яшьлек кенә кала яз булып.

### *Балачак хатирәсе*

Шаян идек, яман булмадык ла,
Араннардан кудык атларны.
Кетәклектән күкәй чәлгәләдек,
Рәнҗетмәдек ләкин картларны.

Наян идек, капка төпләреннән
Утыргычлар күчте күршегә.
Бакчаларга кергәләдек җәен,
Салмадык тик зыян кешегә.

Усал идек, картлар кайчагында
Кызын чыгармаса уенга,
Буралары күчте каршы якка,
Сабак булды гомер буена.

Истәлеге бала чакларымның,
Хәтерләсәң күпме хатирә.
Шаянлыгы малай чакларымның
Уелып ла калган хәтердә.
*** * ***

Бүтән инде язмам дисәм дә,
Үз-үземә вәгъдә бирсәм дә,
Уйлар түзми, җаннан түгелә
Күңелемнән сагыш күленә.

Йолдызлардай уем атыла,
Җиһан буйлап җырым тарала.
Йокысызлык хуҗа төнемә,
Моң уралган һәрбер көнемә.

Ялгыз йөри нигә буйдагың?
Җырсыз калган чишмә буйларың...
Ялгыз йөри нигә кызларың,
Адашкандай читтә казларың?

Сагыну белән тулган күңелем,
Ялгыз сыкрый анда нигезем.
Искә төшә күрше сеңелең,
Моңаямы шуңа күңелем?

Башка инде язмам дисәм дә,
Каләмемне атып бәрсәм дә,
Йөрәгемдә дулый давылмы?
Кем соң саклар, белмим, авылны...

## Замана сагышы

*Тимә әле, картлык, миңа,*
*Яшьнәп каласы килә!*

## ***Кайчакта***

Җырлыйсы килә кайчакта,
Моң таратып җиһанга.
Татар моңы керсен димен
Өмет биреп һәр җанга.

Елыйсы килә кайчакта,
Тарихым искә төшсә.
Елау егет эшемени,
Чит-ятлар әгәр көлсә?!

Дулыйсы килә кайчакта.
Милләтем, телем яна...
Дулап кем соң нәрсә кыра?
Кылган эшебез кая?
Ир-егетләр, сез кайда?!

## ***Заманалар бүтән икән***

Гомер үтә, еллар китә,
Иске дуслар искә төшә.
Изге иде бар нәрсәдән
Дуслык дигән ул төшенчә.

Бүген чоры гел яңача,
Бөтен кайгы — табу акча.
Бер-береңә ярдәм кылу,
Дуслык дигән мәгънә башка.

Заманалар бүтән икән,
Күпме дуслар дөнья куйган.
Узганнарны искә алсаң,
Йөрәк сыкрап куя уйдан...

## ***Нигә юк соң җирдә бәрәкәт?***

Таш сарайлар сала «яңа татар»,
«Мерседес»та чаба малае.
«Юк дөньяда нигә тигезлек?» — дип
Башын вата авыл агае.

Сәбәпләрен эзләп уйга кала:
Элек тә бит булган байлары.
Мәчет салган, хастаханә тоткан,
Дога кылган аңар агае.

Тик нигәдер бүген киресенчә:
Берәү йөзә балда һәм майда,
Икенчесе, ничек җиткерим дип,
Тиеннәрен саный һәр айда.

Ил байлыгы — безнең байлык, диеп
Яшәде ул гомер буена.
Уртак байлык бүген ничек әле
Күчте «яңа татар» баена?

Һәр гамәлнең була нәтиҗәсе.
Тарих бит ул мәңге хәрәкәт.
Бозылганга яшәү кануннары,
Юктыр, ахры, җирдә бәрәкәт.

## ***Үзең сакла***

Нәфес дигән беләм чирне,
Гаип итте бик күп ирне:
Урындагы абзыйларны,
Тарихларда — казыйларны.

Тик бүген дә күп андыйлар.
Нигә сабак соң алмыйлар?

Акча җыя гомер буе,
Байлык туплау бөтен уе,
Айны тартып алыр иде
Үрелеп, әгәр җитсә буе.

Акча санап йоклый алмый,
Төшләрендә гел саташа.
Яман чирдән берүк мине,
Әй Ходаем, үзең сакла.

## ***Шагыйрь***

Башка язмыйм диеп, кайчак
Читкә ташлый каләмен.
Ташлый алмый тик уйларын,
Җанда туган моңнарын,
Милләтенең ачы зарын.
Яза шагыйрь — басылмасмы
Дип йөрәк ярсуларым...

*** * ***

Алла, дибез, килсә без авырлык.
Башка чакта никтер онтыла.
Чәчебезгә инде чаллар кергән,
Ник йөрмибез Алла йортына?

Күпме еллар гәрчә тыйсалар да,
Ак бабамнар качып табынды.
Мөмкинлек бар бүген бушанырга,
Тик мәчетләр никтер ябулы?

Кичке тынлык. Тәмәкене кабам,
Хәмерне дә кайчак капкалыйм.
Чисталыкка тарта мине уйлар,
Күңелемә урын табалмыйм.

Гомеремне очлап ага еллар.
Гөнаһларны юып беразга,
Түбәтәйне киеп, дисбе тартып,
Басарга да вакыт намазга.

## ***Без***

*(Тукайга ияреп)*

Һәркем сайлый дисәләр дә үзе юлны,
Ташлап булмый ләкин язмыш язган юлны.
Кара мәче тырнаса да җаныбызны,
Без хуплыйбыз бик еш кына башкаларны.

Барган сукмак түгел һич тә безләрнеке,
Салган йөге хәтта була читләрнеке.
Кемнәрнеңдер кушылып җырын көйли-көйли,
Сызлатабыз белә торып йөрәкләрне.

Татар каны ага минем тамырларда,
Милләт зары кайный минем җаннарымда.
Илсез, җирсез сукбайларның халәтендә
Каршы барам кайвакытта теләгемә.

Чынбарлыкка күзебезне бер ачмасак,
Татар дигән атыбызны якламасак,
Читләр сүзен әгәр шулай гел сөйләсәк,
Оныкларны, белмим, нәрсә, ни көтәчәк?

## ***Бер үк язмыш***

Баер иде ат, баеса.
Гомере үтте басуда.
Рәхәт күрә алмады тик,
Гел сукада булса да.

Ачлы-туклы тамагы,
Җиләс булды араны.
Язмышына буйсынды,
Шулдыр диеп язганы.

Күрше аранда чабышкы
Сайлап кына солы состы.
Хуҗасына еш кайтарды
Ярышларда ул отышны.

Җитте гомер азагы,
Булды бер үк газабы:
Ит заводы кабул итте
Бер үк көнне аларны.

*****

Беркем белми ни язганын,
Анда ниләр буласын.
Барыбызга, вакыт җиткәч,
Ходай куя ноктасын.

## ***Үзе аера...***

Атсалар да кайчакта таш белән,
Булган чакта күңелем яралы,
Шөкрана кылам язмышыма,
Шулдыр димен миңа язганы.

Сипсәләр дә каныма ачы тоз,
Чыгарсалар җанда ачуны,
Рәнҗетсәләр керсез күңелемне,
Тешне кысып басам ярсуны.

Аңлар өчен бугай бу дөньяны
Ходайның дим шулдыр кушканы.
Табар өчен җирдә хакыйкатьне,
Дуслар белән биргән дошманны.

Үтә алсам әгәр егылмыйча
Язмышыма язган араны,
Хаклык ачар бер көн ялганнарны,
Ходай аерыр актан караны...

## *Иң кыены*

Шакмакларга бүлгәләнгән
Язмыш, шахмат тактасыдай.
Кемнең нәрсә күрәчәген
Күпкә алдан язган Ходай.

Гүя шахмат фигурасы,
Һәркемнең бар үз урыны.
Ялгыш адым ясадыңмы,
Оттырасың уеныңны.

Язмыш, шахмат уеныдай:
Бар ферзясы, бар короле.
Монда бар да үз урнында,
Пешканың да бар үз роле.

Мин дә шахмат тактасында,
Минем дә бар үз уеным.
Шул уенда дөрес адым
Атлый белү — иң кыены.

## *Ике язмыш ике бушлыкта...*

Ике ярны язмыш кавыштырды
Гомерләрнең матур язында.
Мәшәкате белән еллар узды,
Йортта булды сөю, наз гына...

Тупырдашып үсте малайлары,
Яшәделәр онытып иманны.
Әсмабикә сөенеп каршылады
Кичләрендә эштән Иванны.

Гомер үтте, йортка картлык иңде.
Әсмабикә басты намазга.
Иван дәдәй үз китабын алды,
Ул табына башка аллага.

Чуеннар да мичтә аерылды,
Уй-фикерләр тәмам чуалды.
Ике якта аерым түшәк калды,
Гомер җебе кинәт буталды.

Внуклар да инде сирәк кайта,
Алар күптән урыс баласы.
Әсмабикә белми ни кылырга,
Искә ала көн дә Алласын.

Нинди генә киңәш бирергә дә,
Хәлләренә ничек керергә?
Яшьлек хатасының сабакларын
Картайгач шул килә күрергә.

## *Тормыш — театр*

Бу тормыш — тоташ театр,
Анда артист барчасы.
Килә кайчак шул сәхнәнең
Пәрдә читен ачасы.

Барчасы да артист булгач,
Кемнәр соң тамашачы?
Барчабызны артист ясый —
Тормыш кануны ачы!

*** * ***

Шул ук заллар,
Башка затлар.
Күккә иңгән инде күпләр.
Шул ук хәтта кәнәфиләр.

Власть чире каннарында,
Бер уй бары җаннарында —
Югалмасын җылы урын,
Халык чыдам — түзеп торыр.

Еллар үтә шулай җайлап,
Нотык сөйләп, имеш, сайлап.
Тәрәзәдән тарих карый,
Сәясәтне гүя барлап...

## *Килә качасы*

Шигырь язам мин дә өзгәләнеп,
Фикерләрнең җыям кирәген.
Әйтер сүзем калам әйтмичә тик,
Бәргәләнә бары йөрәгем.

Уйларымны кисәм тамырында.
Гел көрәшә акыл һәм йөрәк.
Хак дөресен язсам, кемгә ошар?
Ул хак сүзем кемгә соң кирәк?

Исхакыйны укыйм, Тукаемны.
Хаклык өчен ничек янганнар!
Әйтерсең бер гасыр элек түгел,
Әле кичә генә язганнар.

Шагыйрьләрне барлыйм, Такташымны.

Самимилек, күпме матурлык.
Тарихларда яши шигырьләре —
Өлге итеп ятлап укырлык!

Тарих барлыйм, укыйм дастаннарны.
Бармы бүген шулай язучы?!
Сүз уйнаткан «бөекләрне» күргәч,
Шагыйрьлектән киләчәк качасы.

## ***Юлларым — язмышларым***

Юлга чыккач, кемдер уйга тала,
Кемдер оеп тала йокыга.
Ә мин юлда фикерләрем барлыйм —
Кәгазь-каләм алам кулыма.

Узган юллар — тормыш сынаулары,
Авырлары булды, җиңеле.
Сикәлтәсе, чокыр-чакырлары...
Язмыш шулай сыный шикелле.

Калды анда шатлыклары белән
Илбәк авылы, яңа мәктәбе.
Кырларында алдык мул уңышны,
Күрдек хөрмәт, алдык мәртәбә!

Калды тагын ялгышларым юлда,
Уйланмаган эшләр, хаталар,
Чорның агышына яраклашып
Кабул иткән җайсыз карарлар.

Үткәннәргә үкенмәскә куша
Киләчәккә барыр юлларым.
Алда әле, алда көткәннәрем,
Языласы яңа шигырьләрем,
Җырланмаган әле җырларым...

## ***Яңалык***

*(Шаярып)*

Җәмәгать палатасы —
Бик матур атамасы.
Путин чыгарды указ,
Тик булырмы файдасы?

Тиеш, диләр, җиткерергә
Халык сүзен кирәктә.
Яман карарлар чыкмасын,
Имештер, хөкүмәттә.

Җиткерсәләр фикерне,
Вакытында әмерне,
Бәлки, булыр иде әле
Үзгәртергә дәверне.

*****

Булмас файда тик әлегә,

Җәмәгать, бу палатта.
Чөнки раслыйлар вәкилне
Югары аппаратта.

### *Юк, үкенмим*

Борылам да карыйм үткәнемә,
Кылган эшләр җирдә аз түгел.
Ялгышлары кайчак искә төшсә,
Сызлый йөрәк, сыкрый еш күңел.

Язмышыма, ахры, язылгандыр,
Үзем яздым барыр юлымны.
Кыенлыклар килсә башкаларга,
Суздым һәрчак ярдәм кулымны.

Абынсам да барган сукмагымда,
Сикереп торып кактым тузанын.
Тешне кысып кайчак дошманга да
Булды ярдәм кулы сузганым.

Чордашлардан алда маңгаема
Сызылса да тирән сырлары,
Юк, үкенмим, кабат туры килсә,
Узар идем шушы юлларны...

### *Бер донжуанга*

Сәяхәтче күбәләктәй,
Гөлләргә кунакладың.
Оча да куна, тилгәндәй,
Кызларны кочкаладың.

Синең өчен сөю хисе
Шампан шәрабы кебек.
Бөкесе атылганнан соң
Калды бары тик күбек.

Сандугачтай матур итеп,
Гомер буе сайрадың.
Сизми калдың күке кебек
Ялгыз торып калганың.

Чордашлар бала үстерә,
Синең корсак кабарган.
Башыңа акыл кермәгән,
Чәчең генә чаларган.

### *Кем хуҗа?*

Берләшмәләр төзибез,
Фатирга да түлибез.
Су үтә тик түбәдән,
Кем ябасын белмибез.

Хөкүмәт юлын тапты,
Тапшырды безгә йортны.
Сез, ди, үзегез хуҗа,
Яшәгез күрми нужа...

Суларын да карагыз,
Түбәсен дә ямагыз.
Подъездда чүп ятмасын,
Табыгыз, ди, чарасын.

Ихатада тәртип булсын,
Чит машина тормасын.
Тимер ишек куегыз,
Тыныч кына торыгыз.

Килешүдән күренгәнчә,
Хуҗа икән үзебез.
Нигә акча түлибез?
Шунсын гына белмибез...

## *Зыялы мокыт*

Зыялысы дибез халкыбызның
Зур урында түрә булганны.
Туган телдә сүз катарга курка,
Сәламләми хәтта туганны.

Үз телендә сөйләшүме тагын,
Татарлыктан хәтта ул кача.
Мулла кушкан газиз исемен дә
Яздырган ул инде башкача.

Тукаемны, Такташымны сөйми,
Имеш, алар авыл җырчысы.
Мода өчен затлы китап җыя,
Тик опера, имеш, моңлысы.

Балетларга йөргән була, милли
Театрга тапмый вакытны.
Бу адәмнәр бөек татарымның
Зыялысымы? Әллә мокыты?

## *Урам себерүче*

Күпләр әле уянганчы,
Ул инде йокыдан торган.
Гөлләренә сулар сибеп,
Урамнарны җыештырган.

Ә без һаман сүгенәбез,
Чүп ташлыйбыз, түкерәбез.
Акыллы сүз сөйли-сөйли,
Дөнья ямен бетерәбез.

Әл дә ярый ул бар җирдә
Урамнарны себерергә.
Әллә кайчан чүп астында
Калыр идек үзебез дә...

*** * ***

Юл читендә бер эт ята,

Бер гаепсез, бичара.
...Сәясәттә тапталалар,
Хаклык эзләп... Ни чара.

Халкы өчен гомер биреп,
Янсалар да тарихта,
Күпме шәхес читтә ята,
Кайталмый туган якка.

Мин дә бүген ялгыз эттәй
Бәргәләнәм — бичара.
Үзгәртергә бу дөньяны
Таба алмыйм бер чара.

## *Кем гаепле?*

*(Мәсәл)*

Аю җыйды зур киңәшмә,
Җанварларны киңәшкә.
«Урманда бетте тәртип,
Бозылды халык — нишлик?

Юл салалар, йорт коралар,
Табигатьне бозалар.
Болай булса, озакламый
Безне моннан куалар».

Сүзне алды баш сәркәтип:
«Безнең, — ди, — эштә тәртип.
Йорт салучы һәр адәмнең
Кулында бар «документ».

Су буенда урын беткән,
Коттеджлар тора күптән.
Шуңа хәзер безгә килә
Көн саен әмер өстән.

Рөхсәт кәгазе алынган,
Планнары сызылган,
Табигать министрының
Мөһерләре сугылган».

Җанварлар шаулаштылар,
Вәкилләр сайладылар.
Югарыга юлламага
Кулларын куйдырттылар.

Жалу килгәч, югарыда
Бик озак баш ваттылар.
Гаепле, дип, урманчыны
Эштән алып аттылар.

## *Бер дуска теләк*

Барыбыз да җирдә Алла колы,
Без яшәрбез Ходай язганын.
Язмышлардан узмыш юк, диләр,
Теләк кенә бары калганы.

Теләк булсын язмышыңа тәңгәл,
Урынсызга билләр алышма.
Язганына горур карышсаң да,
Юлдашыңнан ләкин калышма.

Илең өчен, әгәр кирәк булса,
Телең өчен гомер багышла.
Денең өчен фани дөньясында
Курыкмыйча кер син алышка.

Дошманыңа ачу саклама син,
Авыр чакта дусны ташлама.
Күңелеңдә булса тик яхшылык,
Ходай саклар үзе, иншалла!

## *Сез — бәхетем*

Түрә чаклар үтә китә,
Калсын иде җирдә эзем.
Йөрәгемдә туган хисләр —
Шигырьләрем — күңел энҗем.

Чыга җырларым җанымнан,
Илһам бирә киң кырларың.
Сусаганда эчсәм ятып,
Дәрт бирә чишмә суларың.

Кайгы килсә, таянырга
Бар янымда җан дусларым.
Бергәләшеп шатланырга
Якыннарым, туганнарым.

Туган җирдән аермасын
Алда барасы юлларым.
Тәхет түгел, сез — бәхетем,
Туганнарым, җан дусларым.

## *Шундый замана*

Бүген сездән читтә яшәсәм дә,
Якташларым, сездән серем юк.
Гайбәт сүзләр кайчак ишетсәм дә,
Җаным чиста, шөкер, керем юк.

Әйтелмичә калган теләгемне
Табарсыз дим шигырь сүзендә.
Бик еш кына күңлем карышса да,
Каршы бара алмыйм үземә.

Ишетмиләр никтер халык зарын,
Бездән генә тормый карары.
Мәскәүләргә карап яраклашып
Яшәргә шул калды заманы.

## *Алга барам*

Рәнҗетсәләр кайчак урынсызга,
Кадасалар хәнҗәр аркама,
Хаклык җиңәр димен дөньялыкта,
Йөрәгемнән каннар тамса да.

Яраланган юлбарыстай кайчак
Яраларым ялыйм сыкрап.
Яшьләремне күрә алмассыз тик,
Әрнесә дә күңел сулкылдап.

Гасыр аша дәшә ерак бабам,
Күпне күрде татар башы, дип.
Яшим җирдә калсын диеп дәвам,
Алга барам эзем калсын дип.

## ***Кайту***

Җил капканы атлап кердем дә
Сүзсез бактым нигез ташына.
«Кайттыңмы?» — дип гүя тын гына
Әнкәй чыкты кебек каршыма.

Балачагым төште хәтергә,
Табасында коймак чыжлады.
Малай чакка гүя кайтарып,
Самавыры көйләп җырлады.

Кулларымны алып учына,
Күзләремә сөеп карады.
«Озаккамы?» — дигән шикелле,
Әнкәй тагы авыр сулады.

Балачакның гүя кайтавазы —
Ишетелде күке тавышы.
Балачагым төште хәтергә,
Йөрәгемне телә сагышы.

## ***Тимә әле, картлык...***

Санамыйм узган елларны,
Егетләр кебек яшим.
«Бабай», — дип дәшсә оныгым,
Исемә төшә яшем.

Уттай яндык заманында,
Булмадык сүрән күмер.
Саныйсы килми яшемне,
Уйландыра тик гомер.

Әле һаман учаклардай
Дөрләп янасы килә.
Тимә әле, картлык, миңа,
Яшьнәп каласы килә.

*** * ***

Хәйран калдым — горур яңгырый
Татар сүзе бу якларда.
Бергеп калган тау-ташларга
Балкар иле Эльбрус-тауда.

Кайгы-хәсрәт кичә-кичә
Куылса да, кайткан кире.
Саклап калган денен, телен,
Якын туган — Балкар иле.

Кыя таштай горур кала,
Дуласа да җанда давыл.
Язмышыннан кача-кача,
Эльбрус-тауда корган авыл.

Гасырларның кайтавазы —
Онытмыйлар сине, Казан.
Тау-кыялар арасыннан
Ишетелә изге азан.

* * *

Кыска булсак та буйга,
Читтән рәнҗеттермәдек.
Касыкка төртеп булса да,
Алышта җиңдермәдек.

«Зур абзыйлар» белән бүген
Туры килә тартышырга.
Әмма ләкин сәясәттә
Ярамый ялгышырга.

Бу тормышның юллары
Ураулы һәм катлаулы.
Хакыйкатьнең кануннары
Сорый сабыр булганны.

Туры юлдан дөреслеккә
Бик тә кыен җитәргә.
Туры килә сәясәттә
Әйләнгечтән үтәргә.

* * *

Кем соң бүген минем юлдаш?
Узган гомерне буйлыйм.
Ничек яши микән чордаш?
Кылган гамәлне уйлыйм.

Кем соң әле минем моңдаш?
Татар җырын кем җырлый?
Халкым моңын көтә кордаш,
Сорнай гына тик елый.

Дөнья буйлап йөри кардәш,
Белми кемгә таянырга.
Ике туган — бер үк телдәш,
Белми кемгә сыенырга.

Без бит түгел җирдә көндәш,
Берләшалмый башкорт-татар.
Ике туган булса сердәш,
Нишләр иде икән ятлар?

* * *

Ханнар тәхет бүлешкәндә,
Акыл кая калды микән?
Ходай бәхет өләшкәндә,
Татар йоклап ятты микән?

Килгән чакта ятлар явы,
Ханнар кайда булган икән?
Яугирләрнең каны тамган
Газиз җирем янган икән.

Чиркәүләрнең нигезендә
Мәчет ташы елый бугай.
Хуҗа булу үз җирендә
Кайчан язган безгә Ходай?

*** * ***

— Без — татар! — дип лаф орабыз,
Бик еш кына гәп корабыз.
Мулла кушкан атыбызны
Хәтта кайчак онытабыз.

Тел бозабыз тырыша-тырыша,
Чит бер адәм басып торса,
Газиз телем онытыла,
Сүз катабыз гел урысча.

Туй итәбез шау-гөр килеп,
Саклап, имеш, даныбызны.
Чит-ятларга килен биреп,
Ник бозабыз каныбызны?

Кая гына барып чыкма,
Кан кардәше очрап тора.
Мәскәү генә үз җаена
Сәясәтен һаман кора...

# Җырларымнан эзлә

*Уйларымны ләкин минем*
*Үземнән ишетмәссең...*
*Белим дисәң хисләремне,*
*Җырларымнан эзләрсең.*

### ***Онытты***м

Күрешкәч чишмә буенда,
Яратам дигән идең.
Мәңгегә бергә булыйк дип,
Кулларың биргән идең.

Серле иде күзләрең дә,
Сихерле көлгән идең.
Мин синеке, көтәм, диеп,
Вәгъдәләр биргән идең.

Гаепләмим, юлларыңда
Очрады, беләм, бүтән.
Минем дә бәхет башкада,
Оныттым сине күптән.

### ***Әйтмә миңа***

Көзләр шыксыз димә миңа,

Ачы җиле өшетсә дә.
Карашларың җанны эретә,
Ялгызлыкта тилмертсәң дә.

Күзләр моңсу димә миңа,
Кошлар китеп барган чакта.
Синең тавыш, җәйләр буйлап,
Кайтаваздай кире кайта.

Күзләр җансыз димә миңа,
Соңгы яфрак өзелсә дә.
Синең сүзләр, сырхап китсәм,
Дарусыз да бит терелтә.

Күзләр салкын димә миңа,
Карлы яңгыр чылатса да.
Җылы табам кочагыңда,
Җаным хәтта туңган чакта.

## *Җырларымнан эзлә*

Язларында давыл булып
Килә дулап аласы.
Толымнарыңа уралып
Килә синдә каласы.

Күңелеңдә ниләр барын
Килә синең ачасы...
Син яндырган йөрәгемә
Каян дәва табасы?

Күзге салкын яңгыр булып
Килә бер чылатасы.
Кочагыма кысып алып,
Аннан соң җылытасы.

Тургай кебек, баш очыңда
Килә уйнап очасы.
Сиңа багышлана моңлы
Җырларымның барчасы.

Уйларымны ләкин минем
Үземнән ишетмәссең...
Белим дисәң хисләремне,
Җырларымнан эзләрсең.

## *Кар сулары*

*(Җыр)*

Кар астыннан челтер-челтер
Агадыр кар сулары.
Яз кояшы карны ашый,
Җемелди тамчылары.

Кушымта:

Язларында кар сулары
Уята ярсуларны.

Югалтуым, ялгышларым,
Ямансу синсез, ярым.

Соңгы кардан аклык кунып
Кала кебек җаныма.
Язларында аккош кебек
Очамын яннарыңа.

Кушымта.

Аерса да безне көзләр,
Сагынам кар суларын.
Калды серле елмаюың,
Беренче сөйгән ярым.

Кушымта.

*** * ***

Язгы кояш нурларыдай
Тойдым синең карашны.
Үткәннәргә алып чапты
Яшьлекнең чаптар аты.

Язгы судай, җаннарымда
Хисләремне кузгаттың.
Сүнгән хәтер учагына
Гүя утлы куз аттың.

Язгы күкрәү булып кабат
Кагылма хисләремә.
Кал бары хәтер күгендә,
Җылытып читтән генә...

*** * ***

Юлыбыз нигәдер аерылды,
Ә бәлки, язылган язмышка.
Ул көннәр хәтердә булса да,
Соң инде, җанымны кузгатма.

Карашың яндыра очкындай,
Кирәкми, хисләрне уятма.
Сөюең булса да ташкындай,
Юк инде, кирәкми, яратма.

Саф килеш калсыннар хисләрең,
Елмаеп карасын күзләрең,
Хәтердә тик калсын сүзләрең,
Калсыннар күңелдә эзләрең...

## *Яшьлек көлә*

Язлар килә, бар табигать
Бөреләнә чәчәктәй.
Кояш кебек кызлар көлә,
Тавышлары көмештәй.

Әбиләр дә елмаялар,

Кыз чагы искә төшсә.
Чулпыларның серле чыңы
Яшьлеген хәтерләтсә...

Яшьлек көлә, сөю килә
Тургайлар белән бергә.
Язларында күңелемдә
Ачыла гөлләрем дә.

### *Адашыр идем*

Күзләреңнең карасы,
Сихри кашың арасы.
Керфегеңә килә минем
Сөю булып тамасы.

Йөрәгемне яраладың,
Кайдан табыйм дәвасын?
Кичәр идем Каф тауларын,
Анда булса җанашым.

Толымнарыңа уралып
Адашыр идем кабат.
Еллар аша тик елмаеп,
Яшьлектән карый бер зат.

### *Яшь каласы килә*

Яшем илледән узса да,
Матурларга сүз кушам:
«Кызым, син кайсы яктан,
Син кай якларда туган?»

Шаяртып кына булса да,
Чибәрләргә күз кысам.
Өйдәге хатын онтыла,
Танышыйк дигән булам.

Шул чакларда кинәт кенә
Онытым искә төшә,
Оялып куям үзем дә,
Яшем хәтергә килсә.

Юк гаебем минем һич тә,
Начар уй юк күңлемдә.
Күчмәсме дим яшьлекләре,
Гел яшь каласы килә...

### *Бергә кала*

Яраткан саен кайчакта
Суына никтер ара...
Кирәк мәллә мәхәббәткә
Сынауларны узарга?

Мәхәббәткә кирәк, ахры,
Кичәргә ут-суларны.
Ләкин күпләр җиңә алмый

Очраклы ялганнарны.

Кемнәр җиңә ялгышларны,
Кемнәр түзә сагышка,
Гомерлеккә бергә кала
Бербөтен җаннар гына...

### *Сыерчык бураннары*

*(Җыр)*

Язлар җитсә, булып ала
Сыерчык бураннары.
Оныта алмыйм, төшкә керә
Яшьлегем урамнары.

Кушымта:

Сыерчык бураннары,
Юксынам узганнарны.
Хәтер барлый моңсу гына
Яшьлектә калган ярны.

Язгы кичтә җырлап узам
Авылым урамыннан.
Бураннардан сөйгән ярым
Йөгереп чыгар сыман.

Кушымта.

Җитсәм дә гомер көзенә,
Күңелдән чыкмый ярым.
Сыерчык бураннарына
Кереп адашкан парым.

Кушымта.

### *Миңлегөл*

*(Җыр)*

Бакчадагы гөлләремне
Сулар сибеп үстерәм.
Яннарымда булмасаң да,
Төшләремдә еш күрәм.

Кушымта:

Миңлегөлем, әй сеңлем,
Яратамын, шуны бел.
Миңнәреңнән тама гөл,
Ник син минеке түгел?

Очрашканда, күзләреңнән
Сөю сибелә, гөл генәм.
Оялсаң да син әйтергә,
Яратасың, мин беләм.

Кушымта.

Гөл-чәчәкләр арасыннан

Сине эзлим, гөлкәем.
Алыштырмам берәүгә дә,
Син — минем бәгырькәем.

Кушымта.

## *Ул чагында...*

Ул чакта сиңа әйтергә
Сүзләрем табалмадым.
Ут яна бүген йөрәктә,
Соңга калып аңладым.

Хисләремне очрашканда
Тыймаска кирәк булган.
Бүген синең йөрәгеңне
Башкалар чорнап алган.

Язмышларның син — ярында,
Мин — ялгыз атавында.
Бәлки, сөюемне аңлап,
Кайтырсың яннарыма.

Хисләрең кабат ачылыр
Мәхәббәтнең таҗында.
Үпкәләрне читкә ташлап,
Кайтыйк яшьлек язына.

## *Санамыйм*

Көннәремне санамыйм,
Гомерләр уза диеп.
Алдагысын юрамыйм,
Яшим җирдә сөенеп.

Иртәләрен уянам,
Таң атканга куанам.
Тулган ай миңа карый,
Аңлагандай ерактан.

Елларымны санамыйм,
Бар да Ходай язганы.
Булмый көн дә шатлыгы,
Чыгып тора яманы.

Гомеремне санамыйм,
Багам бары узганга.
Яшәве шундый матур
Бу җирдә син булганга.

## *Ләкин...*

Күңелдәге сагышларны
Килә бер таратасым.
Кабат гаярь егет булып
Килә сиңа кайтасым.

Яшь тай кебек болындагы,
Килә ярсып чабасым.
Тилереп бер билләреңнән
Килә кочып аласым.

Иңнәреңә куеп башым,
Килә сүзсез торасым.
Синең болыт чәчләреңә
Килә бер ураласым.

Яктысында серле айның
Шашып үбеп аласым,
Онытып бар дөньясын,
Килә бер яратасым.

Ләкин...
Яшьлек инде узган,
Алсу гөлләре сулган.
Яшьлегемә кайтыр юл юк,
Яшьлек кулмәгем тузган.

## ***Белмим нигә?***

*(Җыр)*

Нигә икән, нигә, иркәм,
Син мине ялгыз иттең?
Юксынып назлы сүзеңне,
Сагыштан елый күңел.

Кушымта:

Сандугачтай очар идем,
Канатларым каерылды.
Белмим нигә, белмим нигә
Безне язмыш аерды.

Җилләр этә сагынганда
Уйларымның җилкәнен.
Ничек кенә теләсәм дә,
Сиңа килеп җиталмыйм.

Кушымта.

Күрәсем килә, күрәсем,
Серең килә беләсем.
Онытып бөтен үпкәмне,
Килә назлап сөясем.

Кушымта.

## ***Сулмасын гөлләрең***

*(Җыр)*

Язларны мин көтәм,
Кошлардай сагынып.
Яшьлеккә очамын,
Тургайдай кагынып.

Кушымта:

Син калдың яшьлектә,
Болында чәчәктәй.
Яшисең күңлемдә

Онытылмас бизәктәй.

Чишмәгә киләм дә
Суларын эчәмен.
Сагышым басылмый,
Тик сине көтәмен.

Кушымта.

Ялгызым урыймын
Болыным буйларын.
Тик сиңа омтыла
Кабаттан уйларым.

Кушымта.

Юк, кайтмас яшьлегем,
Бәхетле көннәрем.
Сулмасын иде тик
Күңелдә гөлләрең.

Кушымта.

### ***Көзге моң***

Сары яфрак оча эзләремнән,
Үткән көннәреннән гомернең.
Моңсу уйлар тама болытлардан,
Сине эзли һаман күңелем.

Ялгыз яфрак — җәйләр хатирәсе
Бөтерелә көзге иртәдә.
Соры бушлык телә күңелемне,
Елмаюың яз китерсә дә.

Гомер язы белән гомер көзен
Бәйли кебек синең эзләрең.
Ялгыз яфрак сине хәтерләтеп
Очып уйный кебек көзләрен...
*** * ***

Каен кызы сагыштамы? —
Иңендә сары шәле.
Баланнарның суыктанмы
Йөзе кызарган мәле.

Өрәңгеләр кайгыдамы? —
Ут яна яфраклары.
Көз кызының колагына
Миләш элгән алканы.

Горур имән, җәй озатып,
Яфрак сибә эзләргә.
Сүрән кояш моңсуланып
Кереп бара көзләргә.

Синең белән мин бәхетле,
Үтсә дә яшьлек яме.
Күңелемдә назың саклый

Иреннәреңнең тәме.

## *Син калгансың*

Искә алам ерак үткәннәрне,
Күңел китә кайчак убылып.
Сабан тургае күк бөтерелә
Күңелемдә уйлар моң булып.

Умырзая кебек, күңелемдә
Елмаюың калган язылып.
Буй-сыннарың йөзә хәтеремдә
Күлдә йөзгән ялгыз кош булып.

Җилләр кебек чаба күңелемдә
Яшьлегемнең чаптар атлары.
Җәйләр булып кайта хәтеремдә
Яшьлегемнең янар чаклары.

Күзләр килде гомер бакчасына,
Җимешләрем анда өлгерә.
Икәү бергә үткән сукмакларга
Яфрак коеп йөри җил генә.

## *Айсылу*

*(Җыр)*

Айдан нурлы йөзләреңә
Карап мин туялмадым.
Толымнарыңа уралу
Бәхетен тоялмадым.

Кушымта:

Кояш кебек Айсылуым,
Юксынам сине, сылу.
Йөрәгемә ник ут салдың?
Синсез миңа ямансу.

Ай янында якты йолдыз,
Син кабындың күгемдә.
Сагышларга салып киттең,
Сагынамын бүген дә.

Кушымта.

Күңелеңә сукмакларны,
Белмим, ничек табасы?
Ике ярда ялгыз калдык,
Килә басма саласым.

Кушымта.

*** * ***

«Үзеңне яратасың», — дип
Бәйләнә миңа хатын.
«Яратам, — дим, яшермичә, —

Шуннан ни гаеп таптың?
Ярата белмәгән үзен,
Башканы ничек сөйсен?!»

### *Мин булырмын*

Сагышлардан җан янганда,
Юлларымда адашканда,
Йөрәгемнән кан тамганда,
Тик син кирәк булдың җанга.

Кәеф-сафа корган чакта,
Акылымны югалтканда,
Син көткәнсең — хәтта җирдә
Барлыгыңны онытсам да.

Алда әле гомер булса,
Үпкәләрең читкә сал да,
Язмыш кая ташласа да,
Мин булырмын синең янда.

### *Өшетсәң дә җанны*

Яшен булып кердең җанга,
Язгы күкрәү калды анда.
Болыт кебек каралсаң да,
Якты хисләр яна җанда.

Карашларың көзге җилдәй
Өшетсә дә җаннарымны,
Уйларымны тыя алмый
Киләм кабат яннарыңа...

*** * ***

Агымсуларда актымы
Яшьлегемнең язлары?
Белсәм дә мин кайтмасыңны,
Көтәм һаман назларың.

Җилләр белән очты микән
Сөям дигән сүзләрең?
Төшкә кереп җанны телә
Синең серле күзләрең.

Карлар булып ява сыман
Сагышларның тузаны.
Сизелми дә калган икән
Гомеремнең узганы.

### *Ярат мине*

Уят мине назлап иртәләрен

Йә алган бул шунда бер әрләп.
Уят мине, онытып үпкәләрне,
Ярат мине кабат иркәләп.

Уят мине, йокламасын җаным.
Сүрелергә сәбәп юк әле.
Тамырларда әле кайный каным,
Хисләремә илһам бир әле.

Уят мине, күңел түрләремнән
Күбәләктәй очып бер әйлән.
Син елмайсаң, яшьлек күкләреннән
Сибелгәндәй була гөл, сәйлән.

Ярат мине, шашып ярат әле.
Сагыш җиле тәрәз какмасын.
Гомер көзе ашыкмасын әле,
Килер юлын әле тапмасын.

Юат мине, бетсен кайгыларым.
Син булганда янда гел бәйрәм.
Әле сиңа тиеш сөю назым
Күңелемдә ята бер бәйләм!

*** * ***

Яшьлек үтте бергә бу якларда,
Каршыладык таңны бергәләп.
Хозурландык язгы болыннарда,
Чатыртауга мендек үрмәләп.

Чишмәләрдән алып моңнарымны,
Суын эчеп басам сагышны.
Еллар узгач кына тик аңладым
Яшьлегемдә кылган ялгышны.

Болыннарда чаба колыннарым,
Хәтер буйлап Акбүз атларда.
Күз алдымнан китми толымнарың,
Син йөрисең икән кайларда?

Тугайларда килә йөгерәсем,
Җитәкләшеп кабат бергәләп.
Тик еракта калган, әй яшьлегем,
Синең сурәт — серле күбәләк.

## *Кирәкми миңа бүтән*

*(Җыр)*

Гомерләр үтә икән,
Үтә дә китә икән.
Сөйгән ярның тәүгесе
Үзәкне өзә икән.

Кушымта:

Сагышларыңа салсаң да,
Күрешүләрне көтәм.
Ярты җаным синдә торып
Калдымы әллә, иркәм?

Җитсә дә гомер көзе,
Йөрәк яшь кала икән.
Сөям дигән сүзләре
Ут булып яна икән.

Кушымта.

Җиләк кебек иренең
Булган мәллә ширбәттән?
Әллә сихерләп киттең? —
Кирәкми миңа бүтән.

## ***Килә бер сөеләсем***

*(Җыр)*

Күңелкәең сандыгының
Табалмыйм ачкычларын.
Мин һаман да аңлый алмыйм,
Кайда соң ялгышларым?

Кушымта:

Язмыш безне таныштырды,
Юллар нигә аерылды?
Суларына салыр идем
Җандагы сагышымны.

Шомырт кара чәчләреңә
Күмеләсем бер килә.
Калды минем күңелемдә
Серле күзләрең генә.

Кушымта.

Сине сагынып үтәр микән
Гел шулай гомерләрем?
Чыкмый һаман исләремнән
Яратам диюләрең.

Кушымта.

*** * ***

Кыш уртасы, тик күңелне
Төреп алды әллә яз?
Җилкендерде йөрәгемне
Яшьлегемнән кайтаваз.

Калдырсам да сиңа сагыш,
Күзләреңдә тойдым наз.
Яңгырады синең тавыш,
Уйнагандай моңлы саз.

Янмасын ла кабат йөрәк,
Сагынуыңны әйтмә, түз!
Яндагысын гына ярат,
Мәхәббәттә инде көз...

## *Китсәм дә бу җирдән...*

Китәрмен беркөнне бу җирдән,
Үлемне беркем дә җиңмәгән.
Гомерләр Ходайдан бирелгән,
Берәү дә мәңгегә килмәгән.

Китәрмен беркөнне бу җирдән,
Сагышлы шәрабым эчелгән.
Гомерләр аерым үтелгән,
Тик хәтер елмая эзеңнән.

Китәрмен беркөнне бу җирдән,
Дөньяда яшәүләр чикләнгән.
Елларым кочса да иңемнән,
Җан туймый һаман да сөюдән.

## *Эчтәлек*


Күңелендә шигырь йөрткән. *Р.Корбан* ........

**Гомерләр үтә икән...**
И туган җир .........................
Чатыртауга менсәм ....................
Син кайдан? .........................
Көзге этюд ..........................
«Тауга карап тау булмадым...» .............
Торналар төшә микән?.. .................
Хәтер барлый... .......................
Бисмилласыз малайлар .................
Кайтыгыз, онытмагыз ..................
Көзге моң ..........................
Күрешәсе килә .......................
«Җырларым сыймый залларга...» ...........
Күңелемдә бер теләк... .................
Моң суза күңелдә ....................
Яңа ел килә .........................
Кайтып килдем .......................
Халык җыры ........................
Моңлану ..........................
«Нихәл анда — Азнакайда?..» .............
«Язларында...» .......................
«Бәхиллеген алмасак та...» ................
Узмасын гомерләр заяга ................
Дуслар кирәк ........................
Кемне көтә? .........................
«Яхшылыктан яман эшкә...» ...............
«Дусларымнан көтеп алкыш...» ............

**Күңелдәге уйлар**
Гөлләр чәчәм ........................
Сезгә бирәм .........................
Үкенмәм ...........................
Түләрмен кебек бурычны... ...............
«Гомерләрне кыска диеп...» ..............
Аерма .............................
Әгәр әйтсәләр... .....................
Көзге уй ...........................
Җаным чиста ........................
Кайтыр идем, әнкәй ...................
Ташлама тик... .......................
Минем еллар ........................
Шигърият ..........................
Тапсын ............................
Сабыр гына .........................
Дусларның чын дигәне... .................
Яхшы сүз ..........................
Кем ышанмый... ......................
Юбилейдан соң .......................

Бер дусны уйлап .....................
Ходай белә... ........................
Үтенеч ...........................
Арала син мине сагыштан... ..............
«Хәмер упкыны йотты...» ................
Дус һәм дошман .....................
Юк, эзләмим... ......................
Сәясәтче була алмам ...................
Янды гомер ........................
«Язлар килде кабат шәһәремә...» ...........
Сезнең белән яшим ...................
Туган як дәвасы ......................
Бүген язам .........................
Яратам мин бу дөньяны .................
«Халкым өчен язам җырларымны...» .........
«Үткәннәрдә хәтер йөри...» ................
«Каләмкәем, рәхмәт укыйм сиңа...» ..........
«Тал егетнең керфегенә...» ...............
Шулай яратылган дөнья... ................
Гафу сорыйм .......................
Гомер эзе .........................
«Дөреслек эзләп барганда...» ..............

**Авылым моңы**

Урыйсы килә кырларны .................
Китеп барышлый... ...................
Кайту... ..........................
Сулыш өрик ........................
Атлар җиктек .......................
Арыш икмәге .......................
Иң зур байлыгым .....................
Җир газабы... ......................
«Тәү кат керде тырма басуларга...» ..........
Авыл мунчасы .......................
«Кул селтим дә шәһәренә...» ..............
Ядкарь ...........................
«Кечке авыл тәрзәсенә...» ................
Авыл һавасы ........................
«Җиргә язлар килгән чакта...» .............
Соңгы җирлек ......................
Уйлар кайта ........................
Туган авылым Үчәлле ..................
Сагынганда ........................
Декабрь яңгыры .....................
Ак әбиләр .........................
Көзге элегия ........................
Көзге рәсем ........................
Хәтер кайта ........................
Барыбызның калыр җире ................
«Кышкы авыл. Кемдер китә...» .............
Арышларым — сагышларым ..............
«Балачакның серле хатирәсе...» .............
«Кышкы иртә, моңсу агачларны...» ..........
Балачак хатирәсе .....................
«Бүтән инде язмам дисәм дә...» ............

**Замана сагышы**

Кайчакта ..........................
Заманалар бүтән икән ..................
Нигә юк соң җирдә бәрәкәт? .............
Үзең сакла .........................
Шагыйрь ..........................
«Алла, дибез, килсә без авырлык...» ..........
Без .............................
Бер үк язмыш .......................
Үзе аера... .........................
Иң кыены .........................
Ике язмыш ике бушлыкта... ..............
Тормыш — театр .....................
«Шул ук заллар...» ....................
Килә качасы ........................
Юлларым — язмышларым ...............
Яңалык ...........................
Юк, үкенмим .......................

Бер донжуанга .......................
Кем хуҗа? ..........................
Зыялы мокыт ........................
Урам себерүче .......................
«Юл читендә бер эт ята...» ................
Кем гаепле? .........................
Бер дуска теләк .......................
Сез — бәхетем .......................
Шундый замана ......................
Алга барам ..........................
Кайту ............................
Тимә әле, картлык... ....................
«Хәйран калдым — горур яңгырый...» .........
«Кыска булсак та буйга...» ................
«Кем соң бүген минем юлдаш?..» ............
«Ханнар тәхет бүлешкәндә...» ..............
«— Без — татар! — дип лаф орабыз...» .........

**Җырларымнан эзлә**

Оныттым ..........................
Әйтмә миңа .........................
Җырларымнан эзлә ....................
Кар сулары .........................
«Язгы кояш нурларыдай...» ................
«Юлыбыз нигәдер аерылды...» ..............
Яшьлек көлә .........................
Адашыр идем ........................
Яшь каласы килә .....................
Бер кала ..........................
Сыерчык бураннары ..................
Миңлегөл .........................
Ул чагында... .......................
Санамыйм .........................
Ләкин... ..........................
Белмим нигә? .......................
Сулмасын гөлләрең ....................
Көзге моң .........................
«Каен кызы сагыштамы?..» ................
Син калгансың ......................
Айсылу ...........................
«Үзеңне яратасың дип», — дип...» ............
Мин булырмын ......................
Өшетсәң дә җанны ....................
«Агымсуларда актымы...» ................
Ярат мине .........................
«Яшьлек үтте бергә бу якларда...» ............
Кирәкми миңа бүтән ..................
Килә бер сөеләсем ....................
«Кыш уртасы, тик күңелне...» ..............
Китсәм дә бу җирдән... .................

Литературно-художественное издание

***Закуан*** *Рустам*
***(Закуанов*** *Рустам Газизьянович)*

## Деревня моя

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Зәкуан*** *Рөстәм*
***(Зәкуанов*** *Рөстәм Газизьян улы)*

## Авыл моңы

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*С.Н.Нуриева*

Корректоры *Р.Н.Нуруллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.02.2008.
Форматы 70г90 1/32. Офсет кәгазе. «Baltica» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 5,85.
Шартлы буяу-оттиск 6,14. Нәшер-хисап табагы 4,32.
Тиражы 3000 д. Заказ Т-145.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahatтм программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.